ШИМБӘ
23 МАРТ
1940 ел
№ 68 (5868)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

СОЦИАЛИСТИК ВАТАН БАТЫРЛАРЫ

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен Кызыл Армиянең начальниклар һәм рядовойлар составын бүләкләү турында бүген „Правда“ да СССР Верховный Советы Президиумының указлары иглан ителә. Советлар Союзы Геройларының мактаулы исемлегенә 171 яңа исем өстәлде. Социализм иленең 23 гаскәри часте, күп меңнәрчә батыр сугышчылар СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнделәр.

Бу указларны бөтен ил тирән канәгатьләнү белән яхшы дип каршы алыр, чөнки алар халыкның теләген, Ватаныбыздагы миллионнарча хезмәт ияләренең хисен чагылдыралар. Героик халык Совет хөкүмәтенең приказын намус һәм дан белән үтәгән героик улларын котлый.

Ленин—Сталин партиясе тәрбияләп үстергән Кызыл Армия данлыклы җиңүгә ирешә. Хәзер Ленинградка һәм СССР ның төньяк-көнбатыш чикләренә куркынычсызлык тәэмин ителде. Сугыш уты кабызучыларның Европаның бу почмагында сугыш уты китереп чыгарырга маташулары җимерелде. Советлар Союзына һөҗүм итү өчен империалистлар тарафыннан күп еллар буена төзелеп килгән ныгытмалар линиясен Кызыл Армия җимерде һәм, шулай итеп, Европаның төньяк-көнчыгышында сугыш җәелдерү турында империалистларның планнарын җимерде. Кызыл Армия дөньяда иң зур эшчеләр үзәге булган Ленинградка туган куркынычны бетерде, үзенең алдына Совет хөкүмәте тарафыннан куелган бурычларны бик яхшы итеп үтәде.

Фин ак гвардеецларына каршы көрәштә Кызыл Армия онытылмаслык батырлыклар күрсәтте. Бу батырлыкларга Совет дәүләтенең верховный органнары лаеклы бәя бирделәр. Данлыклылар исемлегендә—Советлар Союзының яңа Геройлары, очучылар, танкистлар, артиллеристлар, пехотачылар. Монда Кызыл Армиянең бөтен илгә маглүм булган данлыклы командирлары исемнәре белән бер рәттән әле кичә генә рядовой булган сугышчыларның да исемнәре бар. Алар сугышта тиңдәшсез батырлык һәм кыюлык, куркусызлык, тапкырлык һәм җиңүгә тоткарсыз омтылыш күрсәттеләр. Аларның батырлыкларында Ватанга чиксез мәхәббәт, аның куәте өчен, аның чикләренең куркынычсызлыгы өчен бөтен көчне һәм тормышны да бирергә хәзер тору чагыла. Аларның данлыклы эшләрендә Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгәнлек чагыла.

Фин ак гвардеецларына каршы берничә ай буена гына алып барылган көрәш Советлар җире сугышчыларының тиңдәшсез геройлыгы белән тулы. Сугыш заданиесен үтәгәннән соң, моторлары ватылу аркасында, очучы Мазаев кире кайтканда дошман территориясендә җиргә төшәргә мәҗбүр була. Бу, җиргә төшкән самолетны финнәр ерткычлар көтүе булып чолгап алалар, пулеметтан һәм мылтыктан көчле ут ачалар. Иптәшләренең авыр хәлдә икәнлеген күреп, капитан Трусов, үлем куркынычы булуга карамастан, зарарланган самолет янына җиргә төшә һәм 3 совет очучысын дошманнар чолганышыннан коткара.

I нче ранг воентехник иптәш Дудко үзенең танкын дошманның ныгытылган линияләренең иң куркынычлы участкыларына алып бара, люктан башын чыгарып һәм дошман снайперларына каршы пулеметтан көчле рәвештә атып, иптәшләренең тукталган танкын коткара. Яраланган булса да, иптәш Дудко сугышны ташлап китми, бәлки дошманга каршы рәхимсез сугышны дәвам иттерә.

Сапер капитан иптәш Коровин дошманның ДОТ ларын (озак вакытлы ут точкаларын) юк итүгә гаять зур батырлык белән турыдан-туры үзе җитәкчелек итә. Үзенең саперлары белән берлектә ул иң куркынычлы урыннарга үтеп керә һәм һөҗүм итүче дошманга каршы өзлексез ут алып барып, тимербетон ныгытмаларны шартлата.

Илебезнең хәзер Советлар Союзы Геройлары дигән бөек исем алган башка сугышчыларының сугышчан биографияләре дә шундый ук данлыклы героик батырлыкларга күмелгән.

Бу мактаулы исем белән бүләкләнүчеләр арасында югары хәрби командованиенең күренекле вәкилләренең—Кулик, Тимошенко, Мерецков, Птухин иптәшләрнең исемнәрен һәр кем зур канәгатьләнү белән укыр. Оборона халык комиссары урынбасары I нче ранг командарм иптәш Кулик һәм I нче ранг командарм иптәш Тимошенко гражданнар сугышы уты аркылы үткән сугышчан командирлар исәбенә керәләр. Аларны иптәш Сталин „Атлы армиягә нигез салган һәм аны дәһшәтле көч итеп әверелдергән“ кешеләр исәбенә кертә. II нче ранг командарм иптәш Мерецков та гражданнар сугышында актив катнашкан кеше. Бу кешеләр—армиябезнең чәчәге. Алар революциянең беренче көннәреннән үк кулларына корал тотып миллионнарча хезмәт ияләренең бәхетле, азат тормышка хокук алулары өчен, социализм өчен куркусыз көрәштеләр.

Партиянең һәм хөкүмәтнең махсус заданиесен үтәгән вакытта заманында инде бик яхшы батырлык һәм кыюлык күрсәткән Советлар Союзы Герое комдив Денисов икенче „Алтын йолдыз“ медале белән бүләкләнде.

Хәзерге заман армиясенең төп нигезе булган героик Кызыл пехотаның батырлыгы Верховный Совет Президиумы указында бик урынлы күрсәтелгән. Куркусыз пехотачылар артиллеристлар белән, очучылар һәм гаскәрләрнең башка төрләре вәкилләре белән берлектә Маннергейм линиясен һәм аның үтә алмаслык дип саналган тимербетон ныгытмаларын өзделәр. Сугыш тарихында моңа ошашлы вакыйга булмаганлыкны хәтта буржуаз матбугат та икрар итәргә мәҗбүр була! Рәхимсез кыш шартларында, һөҗүм итү өчен урынның чиктән тыш уңайсыз булуына карамастан, тар гына урында Кызыл Армия барлык киртәләрне җиңде һәм партиянең, хөкүмәтнең сугыш заданиеләрен үтәде, совет халкының теләгән тормышка ашырды.

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының сугышчылары һәм командирлары ирекле социализм иленең 183 миллионлы халкының куәтле булышлыгын хис иттеләр. Илебез армияне бик яхшы, өр яңа техника белән, барлык кирәкле нәрсәләр белән тәэмин итте. Ватаныбызның чакыруы белән миллионнарча совет патриотлары сугышка керергә хәзер тордылар. Фронттагы сугышчыларга иге-чиге булмаган Советлар Союзының барлык почмакларыннан кайнар мәхәббәт һәм сәлам җибәрелде. „Халыкның үз армиясенә мәхәббәте нәрсә дигән сүз? Бу, мондый армиянең ныклы тылы булачак, мондый армия җиңелмәслек дигән сүз“ (Сталин).

Советлар Союзы үзе теләгәнен алды. Батыр Кызыл Армиябез социализм иленең төньяк-көнбатыш чикләрен куркынычсыз итеп әверелдерде. Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты Советлар иле хезмәт ияләренең тыныч хезмәтен һәм шатлыклы тормышын тыныч һәм ышаныч белән саклыйлар. Безгә сугыш уты кабызучыларның бер нинди провокациясе дә куркыныч түгел. „Ә зиһеннәре чуалу аркасында Советлар Союзын чынлыкта булганча күрә алмый торган әфәнделәр, Советлар илендәге бөек халыкның үзенең бөек һәм дошманга каршы көрәштә дәһшәтле кораллы көче бар икәнлекне һәм шундый көче булачак икәнлекне аңлаганга кадәр, җиңүчән Советлар Союзының изге хокукларына, җиренә һәм намусына кул сузарга батырчылык итүчеләрнең барсын да һәм һәр кайчан бу кораллы көч тар-мар итәчәклекне аңлаганга кадәр, һәр вакыт тиешле сабакларны алып торачаклар“ (Ворошилов).

Бөек бүләк алу белән рухланган Кызыл Армия сугышчылары, командирлары һәм политработниклары киләчәктә дә хәрби куәтне ныгытырлар, үзләренең коралларын яхшыртырлар, хәрби һәм политик хәзерлекне күтәрерләр. Үткән сугышларның тәҗрибәләре белән баеп алар киләчәктә дә Ватанга чиксез мәхәббәт, хөкүмәтебезгә, Ленин—Сталин партиясенең бөек эшенә чын күңелдән бирелгәнлек үрнәкләре күрсәтерләр.

„ПРАВДА“, 22 нче март.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ НАЧАЛЬНИКЛАР ҺӘМ РЯДОВОЙЛАР СОСТАВЫНА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ИСМЕ БИРҮ ТУРЫНДА

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен **Советлар Союзы Герое** исме һәм бер үк вакытта **Ленин** ордены һәм **„Алтын Йолдыз“** медале бирергә:

1. Кече командир Федор Яковлевич Аккуратовка.
2. Батальонный комиссар Николай Дмитриевич Антоновка.
3. Лейтенант Яков Иванович Антоновка.
4. Капитан Василий Сергеевич Архиповка.
5. Полковник Виктор Ильич Барановка.
6. Капитан Владимир Игнатьевич Белоусовка.
7. Өлкән лейтенант Семен Петрович Березинга.
8. Кече командир Иван Егорович Болесовка.
9. Өлкән политрук Николай Михайлович Брагинга.
10. Кызыл армеец Алексей Иванович Бяковка.
11. Кече лейтенант Гыймазеттин Вәзеттин улы Вәзеттиновка.
12. Кызыл армеец Иван Васильевич Васильевка.
13. Өлкән лейтенант Алексей Михайлович Ватагинга.
14. Кызыл армеец Александр Михайлович Веселовка.
15. Капитан Николай Тимофеевич Видяшевка.
16. Кече командир Андрей Степанович Виноградовка.
17. Капитан Иван Павлович Власовка.
18. Капитан Михаил Михайлович Воронковка.
19. Капитан Юрий Николаевич Гарбкога.
20. Лейтенант Сергей Александрович Говоровка.
21. Комдив Филипп Данилович Гореленкога.
22. Кече командир Егор Гаврилович Горшковка.
23. Кече лейтенант Тимофей Прокофьевич Грачевка.
24. Лейтенант Антон Степанович Грисюкка.
25. Өлкән лейтенант Николай Васильевич Дегтяревка.
26. Кече командир Владимир Филиппович Демурага.
27. Кече командир Алексей Васильевич Дерюгинга.
28. Кече командир Даниил Григорьевич Диденкога.
29. Кече командир Максим Васильевич Дмитриевка.
30. Өлкән политрук Василий Данилович Доценкога.
31. I нче ранг воентехник Федор Михайлович Дудкога.
32. Капитан Анатолий Александрович Дьяконовка.
33. Кече командир Ефрем Арестаулович Дьяконовка.
34. Кече воентехник Николай Александрович Евстратовка.
35. Кече командир Иван Егорович Егоровка.
36. Кече лейтенант Константин Александрович Егоровка.
37. Кече политрук Михаил Иванович Егоровка.
38. Батальонный комиссар Сергей Андреевич Егоровка.
39. Кече командир Николай Константинович Ежовка.
40. Лейтенант Александр Николаевич Елисеевка.
41. Өлкән лейтенант Игнат Дмитриевич Емельяновка.
42. Полковник Евгений Ефимович Ерлыкинга.
43. Кызыл армеец Федор Петрович Жуковка.
44. Кызыл армеец Василий Григорьевич Захаровка.
45. Полковник Михаил Арсентьевич Зашибаловка.
46. Кече лейтенант Михаил Иванович Зубаревка.
47. Кече лейтенант Николай Аксенович Зинченкога.
48. Кече лейтенант Хәбибулла Ибраһим улы Ибраһимовка.
49. Кызыл армеец Петр Григорьевич Ионичевка.
50. Кызыл армеец Намат Караблевка.
51. Лейтенант Тихон Антонович Кацубинскийга.
52. Өлкән политрук Иван Фирсович Квашнинга.
53. Кече командир Вениамин Иванович Кирилловка.
54. Кече командир Михаил Петрович Кирилловка.
55. Кече командир Ларион Павлович Кирпичевка.
56. Комдив Михаил Петрович Кирпоноска.
57. Лейтенант Павел Николаевич Кирьяновка.
58. Өлкән лейтенант Николай Акимович Клыпинга.
59. Батальонный комиссар Анатолий Николаевич Кобликовка.
60. Батальонный комиссар Иван Иванович Кожемякинга.
61. Кече командир Виктор Дмитриевич Козловка.
62. Өлкән политрук Василий Васильевич Койнашка.
63. Өлкән лейтенант Борис Адольфович Колессога.
64. Кече командир Сергей Павлович Комендантка.
65. Лейтенант Борис Александрович Корниловка.
66. Капитан Иван Евдокимович Коровинга.
67. Батальонный комиссар Александр Николаевич Костылевка.
68. Капитан Сергей Иванович Косякинга.
69. Капитан Иван Яковлевич Кравченкога.
70. Лейтенант Анатолий Андреевич Красновка.
71. Капитан Хоти Мекрович Краснокуцкийга.
72. Кызыл армеец Евгений Андреевич Кривойга.
73. Кече командир Федор Федорович Кротовка.
74. Кече командир Алексей Романович Крутоголовка.
75. Кече лейтенант Павел Иванович Крыловка.
76. Кече командир Арсений Петрович Крысюкка.
77. Кызыл армеец Александр Кузьмич Ксенофонтовка.
78. Кече командир Идрис Моисеевич Кудашевка.
79. Өлкән лейтенант Валентин Федорович Кулабуховка.
80. I нче ранг командарм Григорий Иванович Куликка.
81. Кызыл армеец Афанасий Трофимович Куликка.
82. Лейтенант Владимир Михайлович Курочкинга.
83. Полковник Михаил Петрович Кутейниковка.
84. Кече лейтенант Франц Яковлевич Кучеровка.
85. Кече лейтенант Иван Яковлевич Куштинга.
86. Капитан Всеволод Константинович Лаптевка.
87. Өлкән лейтенант Михаил Никанорович Ларинга.
88. Өлкән лейтенант Георгий Петрович Ларионовка.
89. Кече командир Петр Михайлович Леонтьевка.
90. Кече командир Алексей Иванович Лошковка.
91. Политрук Николай Емельянович Лысенкога.
92. Өлкән лейтенант Николай Николаевич Магдикка.
93. Лейтенант Иосиф Исакович Маковскийга.
94. Кече командир Александр Григорьевич Малышевка.
95. Кызыл армеец Александр Иванович Маминовка.
96. Өлкән лейтенант Василий Павлович Маричевка.
97. Капитан Михаил Иванович Мартыновка.
98. II нче ранг командарм Кирилл Афанасьевич Мерецковка.
99. Өлкән лейтенант Василий Михайлович Мешковка.
100. Өлкән лейтенант Василий Иванович Москвинга.
101. Лейтенант Василий Филиппович Музыкинга.
102. Полковник Владимир Варденович Нанейшвилигә.
103. Капитан Сергей Федорович Ниловскийга.
104. Политрук урынбасары Гафият Ярмөхәммәт улы Нигматуллинга.
105. Кече командир Михаил Васильевич Новиковка.
106. Өлкән лейтенант Алексей Егорович Остаевка.
107. Политрук урынбасары Александр Иванович Павловка.
108. Кече командир Федор Павлович Павловка.
109. Комдив Михаил Артемьевич Парсеговка.
110. Лейтенант Петр Устинович Перегудага.
111. Кызыл армеец Иван Федорович Петраковка.
112. Капитан Анатолий Иосифович Петраковскийга.
113. Лейтенант Василий Васильевич Петренкога.
114. Лейтенант Георгий Андреевич Пиняевкә.
115. Кызыл армеец Виктор Кузьмич Пислегинга.
116. Кече лейтенант Иван Иванович Плешковка.
117. Лейтенант Александр Григорьевич Плотниковка.
118. Кече командир Федор Васильевич Прокофьевка.
119. Комкор Евгений Савич Птухинга.
120. Өлкән лейтенант Лев Илларионович Пузановка.
121. Кызыл армеец Бакый Рәхимевкә.
122. Өлкән лейтенант Александр Ефимович Рашивскийга.
123. Капитан Максим Осипович Репейкога.
124. Лейтенант Петр Федорович Распопинга.
125. Кече лейтенант Павел Иванович Рубенокка.
126. Майор Иван Павлович Рослыйга.
127. Кече командир Яков Федорович Руденокка.
128. Лейтенант Никита Иванович Румянцевка.
129. Кече лейтенант Федор Иванович Рябыкинга.
130. Кече лейтенант Хафиз Сабир улы Сабировка.
131. Кече командир Александр Михайлович Саловка.
132. Лейтенант Иван Михайлович Самойловка.
133. Капитан Александр Федорович Семеновка.
134. Өлкән лейтенант Михаил Иванович Осиповичка.
135. Майор Владимир Васильевич Смирновка.
136. Политрук Василий Гаврилович Снагощенкога.
137. Өлкән лейтенант Григорий Максимович Соколовка.
138. Капитан Артем Максимович Сорокага.
139. Капитан Степан Петрович Спирковка.
140. Өлкән лейтенант Георгий Вениаминович Старковка.
141. Кече командир Александр Сергеевич Сулаберидзега.
142. Кече лейтенант Николай Анисимович Сухихка.
143. Кече лейтенант Александр Яковлевич Таракановка.
144. I нче ранг командарм Семен Константинович Тимошенкога.
145. Кече лейтенант Макар Лукич Ткачевка.
146. Майор Николай Степанович Торопчинга.
147. Өлкән лейтенант Борис Павлович Трифоновка.
148. Капитан Михаил Трофимович Трусовка.
149. Майор Евгений Георгиевич Туренкога.
150. Лейтенант Михаил Филиппович Ушаковка.
151. Өлкән политрук Михаил Арсентьевич Фомичевка.
152. Кече командир Александр Федорович Фроловка.
153. Кече лейтенант Василий Михайлович Фроловка.
154. Кызыл армеец Иван Васильевич Хапровка.
155. Лейтенант Иван Александрович Хватовка.
156. Политрук урынбасары Илья Георгиевич Хмаладзега.
157. Өлкән лейтенант Владимир Александрович Хорошиловка.
158. Полковник Аркадий Федорович Хреновка.
159. Лейтенант Анатолий Алексеевич Чепуренкога.
160. Кече командир Михаил Васильевич Чистяковка.
161. Өлкән лейтенант Владимир Ефимович Шарапка.
162. Капитан Василий Васильевич Шаровка.
163. Кече командир Леонид Васильевич Шероновка.
164. Кече лейтенант Александр Васильевич Шиловка.
165. Кызыл армеец Александр Федорович Шихаревка.
166. Лейтенант Петр Васильевич Шутовка.
167. Кызыл армеец Алексей Иванович Щипкинга.
168. Лейтенант Петр Фомич Юрченкога.
169. Политрук урынбасары Василий Николаевич Яковлевка.
170. Кызыл армеец Сергей Христофорович Яковлевка.
171. Лейтенант Сергей Федорович Ячникка.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 21 март, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Кызыл Армиянең гаскәри частьләрен һәм берләшмәләрен СССР орденнары белән бүләкләү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул ук вакытта батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен бүләкләргә:

Ленин ордены белән

70 нче укчы дивизияне,
100 нче укчы дивизияне,
28 нче корпус артиллерия полкын.

„Кызыл Байрак“ ордены белән

7 нче укчы дивизияне,
43 нче укчы дивизияне,
86 нчы моторлаштырылган укчы дивизияне,
138 нче укчы дивизияне,
27 нче укчы полкны,
169 нчы моторлаштырылган укчы полкны,
245 нче укчы полкны,
С. М. Киров исемендәге 20 нче танк бригадасын,
35 нче җиңел танк бригадасын,
136 нчы гаубица артиллериясе полкын,
320 нче пушка артиллериясе полкын,
323 нче артиллерия полкын,
402 нче гаубица артиллериясе полкын,
15 нче тиз очышлы авиация бригадасын,
44 нче тиз очышлы бомбардировка авиациясе полкын,
50 нче тиз очышлы бомбардировка авиациясе полкын,
54 нче тиз очышлы бомбардировка авиациясе полкын,
25 нче истребительләр авиациясе полкын,
Еракка разведка ясый торган 1 нче авиация эскадрилиясен,
Тимер юлларны төзәтүче 1 нче аерым батальонны.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 21 март, 1940 ел.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ГАСКӘРИ ЧАСТЬЛӘРЕН, БЕРЛӘШМӘЛӘРЕН, НАЧАЛЬНИКЛАР СОСТАВЫН ҺӘМ КЫЗЫЛ АРМЕЕЦЛӘРЕН БҮЛӘКЛӘҮ

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үтәгәндә личный состав тарафыннан күрсәтелгән батырлык һәм геройлык өчен ССР Союзы Верховный Советы Президиумы Кызыл Армиянең 23 гаскәри частен Союзның орденнары белән бүләкләде. Шулардан 3 гаскәри часть **Ленин** ордены белән, 20 гаскәри часть—**„Кызыл Байрак“** ордены белән бүләкләнде.

Бүләкләнгән частьләр арасында гаскәрләрнең барлык төп төрләре бар.

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен Советлар Союзы Герое комдив Сергей Прокофьевич Денисов икенче **„Алтын Йолдыз“** медале белән бүләкләнде.

171 командирга, политработникка һәм кызыл армеецка Советлар Союзы Герое исме һәм бер үк вакытта **Ленин** ордены һәм **„Алтын Йолдыз“** медале бирелде.

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул ук вакытта батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен СССР Верховный Советы Президиумы Кызыл Армиянең начальниклар һәм кызыл армеецлар составыннан, начальниклар составы семьяләре членнарыннан, госпитальләрнең һәм гражданский учреждениеләрнең работникларыннан 9.329 кешене Союзның орденнары һәм медальләре белән бүләкләде.

Ленин ордены белән 184 кеше, **„Кызыл Байрак“** ордены белән 1.701 кеше, **„Кызыл Йолдыз“** ордены белән 1.953 кеше, **„Батырлык өчен“** медале белән 2.707 кеше һәм **„Сугышчан хезмәтләр күрсәткән өчен“** медале белән 2.784 кеше бүләкләнде.

Барлык бүләкләнүчеләрнең исемлеге „Красная Звезда“ газетасында иглан ителә.

СССР ның көнчыгыш районнарында социалистик игенчелекнең яңа күтәрелеше өчен

(Новосибирск өлкәсенең авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсендә иптәш А. А. АНДРЕЕВНЫҢ 1940 нчы ел 17 нче мартта сөйләгән речь)

Иптәшләр, бу залда Новосибирск өлкәсенең авыл хуҗалыгында эшләүче алдынгы кешеләре киңәшмәгә җыелганнар. Киңәшмәнең темасы—авыл хуҗалыгы мәсьәләләре. Ләкин сөйләүчеләрнең күпчелеге бу мәсьәләләрдән читкә китте һәм Кызыл Армия турында сөйләде. Моны нәрсә белән аңлатырга? Сөйләүләрдә болай читкә китүләр дөресме? Мин, дөрес дип уйлыйм (**кул чабулар**). Шуның өчен дөрес, чөнки Кызыл Армия безнең совет халкының көндәлек тормышы белән бик нык бәйләнгән. Ул, Ватаныбызга һәм социалистик эшебезгә куркынычсызлыкны көн саен һәм сәгат саен тәэмин итә торган көч. Менә шуңа күрә дә халык, аның аерым вәкилләре үзләренең көндәлек эшләренең нинди генә мәсьәләсен тикшергәндә дә Кызыл Армия турында сөйлиләр.

Бу көннәрдә халкыбызның фикерләре Финляндия фронтында бик яхшы җиңүгә ирешкән һәм чигебезнең бик әһәмиятле участкыларының берсендә СССР га куркынычсызлыкны тәэмин иткән Кызыл Армиягә карата гаят зур шатлык һәм рәхмәт белән юнәлгән (**көчле кул чабулар**).

Ә хәзер, иптәшләр, авыл хуҗалыгының кайбер мәсьәләләренә күчәргә рөхсәт итегез.

Бездә язгы кыр эшләренә кадәр санаулы көннәр генә калып бара һәм язгы чәчүгә хәзерлекне ашыктырырга кирәк.

Барлык мәгълүматларга караганда, 1940 нчы ел иген уңышы өчен уңайлы ел булачак. Көз көне һәм кыш буена булган бик күп явым-төшем яхшы иген уңышы булачакны күрсәтәләр. Ләкин бу билгеләр никадәр генә яхшы булсалар да, җиңү үзлегеннән килмәс, югары иген уңышын алдан хәзерләргә кирәк, аны колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның яхшы эшләүләре белән тәэмин итәргә кирәк.

Авыл хуҗалыгы буенча 1939 нчы елның йомгаклары турында берничә сүз.

Бу йомгакларның нигезе шуннан гыйбарәт ки, ул ел колхоз җәмагат хуҗалыгының тагын да ныгуы елы булды. Бу, колхозларның җәмагат җирләрен әрәм-шәрәм итүдән саклау турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын колхозларда үткәрү нәтиҗәсендә, колхозларның төп базасын, аларның җәмагат җирләрен әрәм-шәрәм итүнең бетерелүендә, ә каралты тирәсе җирләрен үлчәгән вакытта авыл хуҗалыгы артеле уставындагы нормалардан артык булган шактый күп сандагы җирләрнең яңадан колхозларга кайтарылып бирелүендә һәм аларның җәмагат җирләренә кушылуында чагылды. Ләкин эш монда гына түгел. Әһәмиятлесе шунда ки, бу карар колхозларның җәмагат хезмәтендә колхозчыларның катнашуы тагын да үсүне тәэмин итте. Аерым өлкәләрдән һәм районнардан алынган саннарга караганда, аз санда хезмәт көннәре эшләгән колхозчылар саны бик нык кимегән һәм күп санда хезмәт көннәре эшләүче колхозчылар саны шактый арткан. Мәсәлән, Новосибирск өлкәсендә һәм Алтай краенда 1939 нчы елны колхозчыларның гаять зур күпчелеге 200 хезмәт көне һәм аннан да артыграк эшләгәннәр.

Колхозларда җәмагат терлекләре саны арткан. 1938 һәм 1939 нчы елларда атлар саны 1.700.000 башка; мөгезле эре терлекләр—3.000.000 башка; сарыклар—9.500.000 башка; дуңгызлар—1.000.000 башка арткан. Тулы булмаган саннарга караганда, „Колхозларда җәмагат терлекчелеген үстерү чаралары турында“ СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары игълан ителгән вакыттан алып 1940 нчы елның 1 нче январена кадәр инде колхозларда 96.800 яңа терлекчелек фермалары оештырылган, шул исәптән мөгезле эре терлек фермалары—29.900, дуңгыз асраучылык фермалары—25.400 һәм сарык асраучылык фермалары—41.500.

1939 нчы ел шулай ук авыл хуҗалыгы алдынгыларының бик яхшы яңа уңышлары елы да булды. Шуның өстенә күп сандагы рекордларны Себер колхозчылары бирделәр.

1940 нчы елгы авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашучылар саны үткән елга чагыштырганда шактый үсә. 1939 нчы елны авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә 16.000 колхоз, 293 МТС һәм 761 совхоз катнашкан иде, ә барлык катнашучылар 193.000 иде.

1940 нчы елга, күргәзмәнең Баш Комитеты биргән тулы булмаган саннарга караганда, күргәзмәдә катнашу шартларына җавап бирерлек 31.000 колхоздан, 818 МТС тан һәм 1.660 совхоздан гариза кергән, ә барлыгы инде 431.000 кандидаттан гариза бар. 1939 нчы елны Новосибирск өлкәсеннән күргәзмәдә катнашучылар 3.287 иде, ә 1940 нчы елны 7.202 кандидаттан гариза алынды.

Шушы чагыштырудан 1939 нчы елның яңа уңышларны, авыл хуҗалыгы өлкәсендә яңа рекордларны тәэмин итүдә нинди бай ел булганлыгын күрергә мөмкин. Бу уңышларга һәм рекордларга большевистик партиябезнең дөрес политикасы һәм колхозларны ныгыту өстендә эшләве нәтиҗәсендә, авыл хуҗалыгы турында һәм колхозчы крестьяннар турында иптәш Сталинның һәр вакыт кайгыртучанлыгы нәтиҗәсендә ирешелде (**көчле кул чабулар**).

1939 нчы ел колхозларда хезмәт җитештерүчәнлегенең тагын да үсүе елы булды. 1939 нчы елны СССР ның күп кенә өлкәләре өчен, мәсәлән, корылык булган Волга буе һәм үзәк өлкәләр өчен һава шартлары шактый начар булуга да карамастан, 1938 нче елга чагыштырганда бөртекле ашлык уңышы күбрәк алынган булу шактый гына дәрәҗәдә шуның белән аңлатыла.

Шулай булса да, хезмәт җитештерүчәнлеге үсеп баруга да карамастан, киләчәктә дә авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да күтәрү төп бурыч булып кала.

I. АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА ХЕЗМӘТ ҖИТЕШТЕРҮЧӘНЛЕГЕН КҮТӘРҮ ТУРЫНДА

Колхозларда хезмәтнең ялгыз крестьян хуҗалыгында булганга чагыштырганда шактый нәтиҗәлерәк икәнлеге дөрес. Халык Хуҗалыгы Учеты Үзәк Идарәсе саннарына караганда колхозларда бер центнер ашлык җитештерүгә моннан элек ялгыз крестьян хуҗалыкларында тотылганга караганда өч тапкыр кимрәк хезмәт тотыла. Билгеле, бу, колхоз строеның иске индивидуаль крестьян хуҗалыгын хәл иткеч җиңүе. Ләкин без авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлегенең хәзерге дәрәҗәсе белән канәгатьләнә алмыйбыз, чөнки бездә тагын да югарырак хезмәт җитештерүчәнлегенә ирешү өчен бөтен мөмкинлекләр тупланган. Беренчедән, моны авыл хуҗалыгының тракторлар, авто-машиналар, комбайннар һәм башка төрле авыл хуҗалыгы машиналары белән гаять дәрәҗәдә механикалашкан булуы күрсәтә. Икенчедән, изоляцияләнгән ялгыз крестьян хуҗалыгындагы хезмәткә караганда колхозларда җәмагат хезмәтенең күп дәрәҗәдә нәтиҗәлерәк булуы күрсәтә. Өченчедән, бер центнер ашлык җитештерүгә ялгыз крестьян хуҗалыгында тотылганга караганда өч тапкыр гына түгел, бәлки биш-ун тапкыр кимрәк хезмәт куя торган алдынгы колхозларның, совхозларның, МТС ларның һәм авыл хуҗалыгы алдынгыларының югары хезмәт җитештерүчәнлегендә гаять күп тәҗрибә туплаган булуы күрсәтә.

Авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү күбрәк продуктлар булдыру өчен, продукцияне эшләп чыгаруга азрак хезмәт куеп, күбрәк продуктлар җитештерү һәм колхозларның, колхозчыларның тагын да таза тормышлы булуларын тәэмин итү өчен кирәк. Җир безне бик аз гына да чикләми һәм кичә монда бездә җир начар түгел, бәлки аны начар эшләү бар дип бик дөрес әйттеләр. Безнең социалистик хуҗалыгыбызда хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү мөмкинлекләре чикләнмәгән.

Авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең иң якындагы чыганаклары нәрсәдә? Алар күп, мин аларның кайберләрен генә китереп үтәм.

Беренче чыганак. МТС ларның һәм совхозларның эшен яхшырту, тракторлардан, комбайннардан һәм башка төрле авыл хуҗалыгы машиналарыннан нәтиҗәлерәк файдалану. Алдынгы МТСлар һәм совхозлар, тракторчылар һәм комбайнчылар күрсәткәнчә, монда мөмкинлекләр чиксез күп. Менә берничә сан. 15 ат көчле тракторга күчереп исәпләгәндә СССР да 1939 нчы елны (шартлы сөрү белән алганда) уртача 413 гектар җир сөрелде, бу—АКШ тагы тракторларның эшләвеннән 3 тапкырдан күбрәк артык. Анда бер трактор 111 гектар эшли. Бу—капиталистик һәм фермерлар хуҗалыгына караганда безнең социалистик игенчелегебезнең өстенлеген күрсәтә. Ләкин МТС ларда һәм совхозларда тракторлардан нәтиҗәле файдалану әле җитәрлек түгел дип табылырга тиеш.

Себер крайларында һәм өлкәләрендә тракторлардан файдалануны алып карыйк. 1939 нчы елны Новосибирск өлкәсендә бер тракторга 369 гектар, Омск өлкәсендә 350 гектар, Алтай краенда 347 гектар һәм Красноярск краенда 369 гектар, ягъни хәтта СССР да булган уртачадан да кимрәк эшләгән.

Шул ук вакытта алдынгы трак-

торчылар берничә тапкыр күбрәк эшлиләр. Новосибирск өлкәсендәге Купино МТС ында трактор отряды бригадиры иптәш Овчинников 1939 нчы елны ЧТЗ тракторы белән 2.665 гектар эшләгән, СССР да исә уртача 998 гектар эшләнгән. Рязань өлкәсенең Можары МТС ында трактор отрядының атаклы бригадиры иптәш Бортаковский 1939 нчы елны ЧТЗ тракторы белән 6.022 гектар эшләгән. Азербайҗан ССР ның Таузы МТС ы тракторчысы Муса иптәш Алиев көчле СТЗ тракторы белән 1.207 гектар эшләгән. Менә шундый алдынгы тракторчылар бездә берәрләп кенә түгел. Алар йөзләрләп һәм меңнәрләп. Бу алдынгы тракторчылар һәм комбайнчылар турында бер [illegible] гына бит дип әйтергә мөмкин. Бу дөрес түгел, чөнки югарыда әйтелгән уртача эшләп чыгарудан бер ярым—ике тапкыр күбрәк эшләгән йөзләрчә МТС лар һәм совхозлар бар. Сезнең Себердә дә андый МТС лар бар. Новосибирск өлкәсенең Ярково МТС ы 1939 нчы ел 15 ат көчле бер трактор белән 661 гектар эшләгән. Алтай краеның Веселоярск МТС ы 583 гектар эшләгән.

МТС ларда һәм совхозларда хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү мөмкинлекләре бик күп икәнен шундыйлар [illegible].

Ә МТС ларда тракторларның җитештерүчәнлеген СССР да уртача 10 процентка гына булса да күтәрү ни дигән сүз? Бу, өстәмә рәвештә тракторлар белән елга да 20 миллион гектар чамасы җир сөрү дигән сүз. Ә күп МТС лар, бигрәк тә туңга сөрү буенча, үзләренең трактор эшләре планнарын елдан-ел үтәми киләләр.

Алыйк комбайннарны. 15 футлы комбайнга күчереп исәпләгәндә 1939 нчы елны СССР да уртача 277 гектар урып-җыелган. Новосибирск өлкәсендә комбайн белән 273 гектар, Красноярск краенда 251 гектар һәм Алтай краенда 255 гектар урып-җыелган. Шул ук вакытта Новосибирск өлкәсендә комбайнчы иптәш [illegible] 3 комбайн тагып 3.000 гектар урып-җыйган. Шул ук өлкәдә Тройцкое МТС ында комбайнчы иптәш Самылов „Коммунар“ комбайны белән 820 гектар, ә Чкалов өлкәсенең Ташлы районындагы Большевистский МТС комбайнчысы иптәш Варакин ике комбайн тагып 3.420 гектар урып-җыйган. Аерым алдынгы комбайнчылардан башка тагын СССР дагы уртача саннардан бер комбайн белән бер ярым—ике тапкыр артыграк эшләүче МТС лар һәм совхозлар да аз түгел.

Ә МТС ларда комбайннарның җитештерүчәнлеген 10 процентка гына булса да арттыру ни дигән сүз? Бу, комбайннар белән өстәмә рәвештә 5 миллион гектар чамасы урып-җыю дигән сүз.

Тракторларның һәм комбайннарның җитештерүчәнлеген ничек тормышка ашырырга? МТС ларның эше турында СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының „Машина-трактор станцияләренең эше турында“ гы 1939 нчы ел 13 нче январь карарында бөтен тулылыгы белән әйтелгән. Кызганычка каршы, күп кенә МТС лар партиянең һәм хөкүмәтнең бу карарында күрсәтелгән барлык карарларны да тормышка ашырмаганнар әле. МТС һәм совхоз работниклары тракторлардан һәм комбайннардан нәтиҗәле файдалануны арттыра алалар һәм арттырырга тиешләр.

Икенче чыганак. Колхозчыларның хезмәтен тагын да дөресрәк оештыру. Күп кенә колхозлар бригадаларда хезмәтне звенолап оештыру юлы белән бу бурычны уңышлы хәл итәләр инде.

Партиянең XVIII нче съезды өченче бишьеллык план турындагы карарында болай дигән: „Колхоз дисциплинасын тагын да ныгытырга һәм колхозчыларның бөтен массасы арасында тиешле тәрбия эшен көчәйтергә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрергә һәм яхшы эшләүче колхозчыларны кызыксындырырга, шулай ук колхозларда звенолар системасын киң кулланырга кирәк“. Шушыннан соң күп кенә республикаларда, крайларда һәм өлкәләрдә колхоз бригадаларында звенолар саны шактый артты.

Звенолар чөгендер, мамык, җитен һәм тары кебек культураларда үзләрен тулысынча күрсәтә алдылар. Шулай ук алар бодай да һәм башка [illegible] да да [illegible]. Моны, шул исәптән Новосибирск, Омск өлкәләре, Алтай һәм Красноярск крайлары [illegible] культуралар буенча массовый төстә [illegible] тәҗрибәсе күрсәтә.

Хезмәтне звенолап оештыруның өстенлеге нәрсәдә? [illegible] Звенолар 50—80 кешедән тора торган бригадалардан [illegible] бригадаларда звенолар чын[illegible] колхозчыларның хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә зур ча-

ра. Бу җитештерүчәнлек эшләнгән хезмәт көннәре санында гына түгел, бәлки иген уңышының югары булуында да чагыла. Шуңа күрә дә үз бригадаларында звенолар оештырган колхозларның [illegible] тиҗәләр алуы очраклы хәл түгел. Шуңа күрә дә авыл хуҗалыгы алдынгыларының иген уңышы буенча иң югары рекордлары [illegible] очраклы хәл түгел. [illegible]

Өченче чыганак. Эш нормаларын ачыктан-ачык искергән һәм күп кенә еллар буена яңадан каралмаган һәм арттырылмаган [illegible] эш нормаларын акрынлап яңадан карап чыгу кирәк.

Бик күп кенә колхозлар күптән үк инде 1934 нче елны Наркомзем раслаган уртача нормаларны арттырып үтиләр. Бу колхозларда колхозчыларның хезмәт җитештерүчәнлеге үсте һәм [illegible], ләкин күп кенә еллар буена әле шул ук искергән нормалар белән эшләп килүче колхозлар да аз түгел, бу хәл [illegible] хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүгә һәм хезмәт көненең бәясен арттыруга тоткарлык ясый.

Дүртенче чыганак. Авыл хуҗалыгы алдынгыларының массовый хәрәкәтен тагын да җәелдерү. Бу хәрәкәтнең гаять зур революцион әһәмиятенә 1935 нче елны Кремльдә стахановчылар киңәшмәсендә иптәш Сталин тулы бәя биргән иде инде.

Һәрбер колхозның, совхозның һәм МТС ның үзенең алдынгыларын булдырырга һәм алар белән горурланырга тулы мөмкинлекләре бар. Колхозларның, совхозларның һәм МТС ларның бурычы—авыл хуҗалыгы алдынгыларының тәҗрибәсен [illegible] да киңрәк кулланырга [illegible]. Авыл хуҗалыгы алдынгыларының тәҗрибәсе шуны күрсәтә ки, [illegible] мөмкинлекләре чыннан да зур. Шушында [illegible] Новосибирск өлкәсендәге алдынгыларның [illegible] алып карыйк. Новосибирск өлкәсендә бәрәңгенең уртача уңышы гектарыннан 104 центнер булган, ә менә иптәш Юткина үзенең звеносы белән бер гектардан 1.217 центнер бәрәңге һәм 4 гектар мәйданның һәр гектарыннан 944 центнер бәрәңге алган (**кул чабулар**). Иптәш Кострикина үзенең звеносы белән 7 гектар мәйданның һәр гектарыннан 453 пот һәм 120 гектар мәйданның һәр гектарыннан 200 пот бодай уңышы алган (**кул чабулар**). Шулай ук монда утыручы күп кенә башка алдынгыларның күрсәткечләре [illegible]. Билгеле, моңа [illegible] берьюлы гына ирешә алмый. Юткина һәм Кострикина иптәшләр дә шулай ук бердән ирешә алмаганнар, моның өчен аларга 3—4 ел буена [illegible] тырышып эшләргә кирәк булган. Ләкин авыл хуҗалыгы буенча безнең алдынгыларыбыз ирешә торган уңышлар хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен чикләнмәгән резервлар һәм мөмкинлекләр барлыгын күрсәтә.

Ә сез, алдынгы иптәшләр, алга барыгыз, ирешелгәннәр белән тукталып калмагыз һәм үзегезнең тәҗрибәгезне кечкенә участоклардан зур мәйданнарга күчерегез, артта калучы колхозчыларны [illegible] һәм үз артыгыздан ияртеп барыгыз.

Авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү чыганаклары шулар.

Болар барсы да безнең край, өлкә һәм район совет һәм партия оешмалары өстенә авыл хуҗалыгы—колхозлары, МТС лары һәм совхозлары эшенә [illegible] җитәкчелек итүне [illegible] рәвештә яхшырту бурычын йөкли. Иптәш Сталин безнең партия һәм совет җитәкчеләрен [illegible] шуңа өйрәтә (**көчле кул чабулар**).

II. СССР НЫҢ КӨНЧЫГЫШ РАЙОННАРЫНДА АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫН ТАГЫН ДА КҮТӘРҮНЕҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Мин тукталырга теләгән икенче мәсьәлә, ул—Советлар Союзының авыл хуҗалыгында безнең көнчыгыш районнарыбызның әһәмияте турындагы мәсьәлә.

Сез Новосибирск өлкәсендәге, күршедәге крайлардагы һәм өлкәләрдәге авыл хуҗалыгы алдынгыларына һәм колхозчыларга карата киңәшмә исеменнән мөрәҗәгать кабул итәргә телисез. Бу дөрес. Новосибирск өлкәсенә һәм көнчыгыштагы башка өлкәләргә һәм крайларга партиянең XVIII нче съездында иптәш Сталин тарафыннан авыл хуҗалыгы алдына куелган бурычларны үтәүгә үзләренең конкрет төстә катнашуларын билгеләргә вакыт инде. Иптәш Сталин болай дигән иде: „Иң якындагы 3—4 ел эчендә гектарыннан уртача 12—13 центнер уңыш алып ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү өчен, техник культуралар җитештерүне уртача 30—35 процентка арттыру өчен, сарыклар һәм дуңгызлар санын ике өлеш, мөгезле эре терлекләр санын 40 процент чамасына, атлар санын 35 процент чамасына арттыру өчен игенчелегебезнең һәм терлекчелегебезнең күтәрелүен тагын да җәелдерергә“. Безнең көнчыгыш районнарыбызның, шул исәптән Новосибирск өлкәсенең дә мөмкинлекләрен тикшерә башласаң, һичбер икеләнмичә әйтергә мөмкин, Новосибирск өлкәсе һәм башкалар,—мин монда Омск өлкәсен, Алтай һәм Красноярск крайларын һәм һава һәм туфрак шартлары ягыннан шулар белән бер дәрәҗәдәрәк тора торган Чиләбе өлкәсен, шулай ук Казагстан ССР ның Павлодар, Төньяк Казагстан, Кустанай, Караганды, Көнчыгыш Казагстан өлкәләрен күздә тотам,—болар 1938 нче елны җитештергән 1,5 миллиард пот ашлык урынына ел саен ашлык җитештерүне 2—3 ел эчендә һич югында 2—2,5 миллиард потка кадәр арттыра алалар (**кул чабулар**). Бу өлкәләр терлекләр санын уңышлы рәвештә бер ярым тапкыр арттыра алалар (**кул чабулар**). Һәм бу, иптәшләр, арттырып әйтү булмас, чөнки бу өлкәләрдә һәм крайларда авыл хуҗалыгын тиз үстерү өчен гадәттән тыш уңайлы шартлар бар.

Бу крайлардагы һәм өлкәләрдәге кайбер аерым районнар соңгы ике ел эчендә бөртекле ашлык буенча шактый югары уңышка ирештеләр инде. Мәсәлән, Красноярск краенда Пировское районы 1939 нчы елны бөтен районда гектарыннан 20,8 центнер, Шира районы 16,7 центнер сабан бодае уңышы алды. Новосибирск өлкәсендә Ленинский районы гектарыннан 17,8, Кемерево районы 16,6, Топкино районы 16,6 центнер бөртекле ашлык алды. Казагстан ССР ның Төньяк Казагстан өлкәсе 1938 нче елны бөтен өлкәдә гектарыннан 20,2 центнер бөртекле ашлык уңышы алды. Димәк, кайбер районнарда һәм өлкәләрдә инде без үзебезнең мөрәҗәгатебездә язарга уйланган уңыштан—гектарыннан йөз поттан күбрәк уңыш алынган.

Мин көнчыгыш районнарда авыл хуҗалыгы өчен гаять уңайлы шартлар турында сөйләдем. Алар нәрсәдән гыйбарәт? Алыгыз җир турындагы мәсьәләне. Безнең илебездә көнчыгыш районнарында булган кебек киң җирләр кайда бар соң? Чагыштыру өчен мин көнчыгыш өлкәләрдәге колхозларда бер колхоз йортына күпме җир һәм СССР ның башка өлкәләрендә күпме җир туры килгәнлекне күрсәтә торган кайбер саннарны китерергә теләр идем. Украинада бер колхоз йортына 9 гектар, Калинин өлкәсендә 14 гектар, Москва өлкәсендә 8 гектар, Воронеж өлкәсендә 11 гектар, Курск өлкәсендә 10 гектар җир туры килә, ә Красноярск краенда 59 гектар, Новосибирск өлкәсендә 49 гектар, Омск өлкәсендә 49 гектар, Алтай краенда 47 гектар һәм Чиләбе өлкәсендә 40 гектар туры килә.

Мин санап үткән уннан артык көнчыгыш өлкәләрендә һәм крайларында сөрергә яраклы җирләр 39 миллион гектар, болынлыклар 19 миллион гектар һәм көтүлекләр 35 миллион гектар. Әлегә кадәр эшләнмичә яткан 14 миллион гектар чамасы җир игенчелеккә файдаланылмаган. Менә сезгә җир мөмкинлекләре.

Алыйк туфрак шартларын. Көнчыгыш районнарда туфракның күпчелеге—череге бик күп булган, кара-коңгырт төстәге, хәзергә әле сөрелмәгән, таркалмаган, яхшы структуралы, урман-дала туфраклары, ягъни югары уңыш өчен иң яхшы туфраклар.

Көнчыгыш районнарда һава шартлары гадәттән тыш яхшы. Анда корылык сирәк күренеш. Соңгы илле ел эчендә Волга буе һәм көньяк өлкәләрендә корылыклы 17 ел булган булса, Себердә алар бары 5 кенә булды, анда да әле корылык зур территориягә җәелмәде. Димәк, монда һава бер төрле тора. Күп санлы су бассейннары, елгалар, күлләр,

(Ахры 3 нче биттә).

ИПТӘШ А. А. АНДРЕЕВ РЕЧЕ

(Ахры. Башы 2 нче биттә).

көнчыгыштагы коры җиллләрдән саклый торган Саян һәм Алтай таулары, зур урманнар, болар барсы да ныклы һәм югары иген уңышы өчен уңайлы шартлар тудыралар.

Сабан бодае һәм бәрәңге уңышы буенча иң югары рекордларның Себер туфракларында һәм Себер шартларында ирешелгән булуы очраклы хәл түгел. Ефремов, Кострикина, Чуманов, Юткина, Сергеева һәм башка иптәшләрнең Себер туфракларында бөртекле ашлык һәм бәрәңге буенча күренекле рекорд уңышлары алулары очраклы хәл түгел. Безнең көнчыгыш районнарыбызда сабан бодайларының аксым ягыннан Канадада һәм башка илләрдә булганга караганда югарырак сыйфатлы булуы очраклы хәл түгел.

Совет власте Себерне тамырыннан үзгәртте. Элек ярым сахра, каторга һәм сөрген җире булган Себер хәзер СССР ның югары дәрәҗәдә механикалаштырылган авыл хуҗалыгы булган районы, промышленность районы булып әверелде. Менә авыл хуҗалыгын механикалаштыру турындагы кайбер саннар. 1939 нчы елны Алтай, Красноярск крайларындагы, Новосибирск һәм Омск өлкәләрендәге колхоз һәм совхоз кырларында 47.000 трактор, 23.000 комбайн, 22.000 авто-машина эшләде. Бу крайлардагы һәм өлкәләрдәге МТС лар гына да 1940 нчы елны 4.000 гә якын яңа трактор һәм 3.000 комбайн алалар. Бу өлкәләрдә тракторлар барлык җирләрнең 80 процентын сөрәләр, ә комбайннар белән барлык бөртекле ашлык мәйданының 70 проценттан артыграгы урып-җыела. Авыл хуҗалы механикалашуның бу дәрәҗәсе безнең башка күп кенә өлкәләребездәге механикалашу дәрәҗәсеннән югарырак.

Димәк, көнчыгыш районнарда күп җир генә түгел, яхшы туфрак һәм уңайлы һава шартлары гына түгел, бәлки югары дәрәҗәдә механикалаштырылган авыл хуҗалыгы һәм колхозларда, МТС ларда һәм совхозларда күп санлы үсеп җиткән кадрлар да бар. Шулай итеп, авыл хуҗалыгының көчле рәвештә үсүе өчен бөтен шартлар бар.

Менә шуңа күрә дә, иптәшләр, безнең көнчыгыш өлкәләребез иң якын елларда социалистик илебезнең төп игенчелек районнарыннан берсе булып әверелергә тиешләр.

Мин Себердә берничә тапкырлар булдым һәм аны бераз өйрәндем инде һәм турыдан-туры әйтергә кирәк, безнең гаять бай көнчыгыш районнарыбызда булган барлык мөмкинлекләргә таңга каласың.

Көнчыгыш өлкәләрдәге һәм крайлардагы колхозларның һәм совхозларның социалистик игенчелектә гаять зур уңышлары бар инде. 1928 нче елдан 1938 нче елга кадәр ун ел эчендә Чиләбе, Омск, Новосибирск өлкәләрендә, Алтай һәм Красноярск крайларында бөртекле ашлык уңышы гектарыннан уртача 9,5 центнерлан 13 центнерга кадәр күтәрелде. Бу 5 өлкәдә һәм крайда валовой ашлык җитештерү ун ел эчендә 600 миллион поттан 1 миллиард 100 миллион потка кадәр артты. Икенче бишьеллыкта Себер өлкәләрендә һәм крайларында яңадан 6 миллион 500 мең гектар җир үзләштерелде. Себер авылы крестьяннәре өчен колхозларда тормыш тамырыннан үзгәрде, культуралы, таза тормыш булып әверелде.

Ләкин шул ук вакытта, иптәшләр, мин инде әйткәнемчә, сездә ашлык җитештерүне арттыруда тагын да тизрәк алга бару өчен, терлекләр санын һәм терлекләрнең продуктлылыгын шактый күтәрү өчен гаять зур мөмкинлекләр бар. Моның өчен көнчыгыш районнардагы колхозлар, совхозлар, МТС лар, шулай ук партия һәм совет оешмалары нәрсә эшләргә тиешләр?

Игенчелеккә җитәкчелек итүдәге зур кимчелекләрне бетерергә, җирне эшкәртүне кискенлек белән яхшыртырга, басуларны чүп үләннәреннән тазартырга кирәк. 1938 нче елны яңа игеннәрне урып-җыю вактында Омск, Новосибирск, Чиләбе өлкәләре һәм Алтай крае кырларында булырга туры килде. Мин әйтергә тиешмен, кай вакытларда кайбер колхозларның һәм хәтта совхозларның да кырларында үсеп утыра торган нәрсәләрнең чүп үләннәреме—әремме, сарутмы, сөтлекме һәм башка төрле чүп үләннәреме, әллә чәчүлекләрме икәнлеген аңлау кыен иде, ә алар чәчүлек булганнар икән. Шуңа күрә дә мондый кырларны урып-җыйганда комбайнчылар бик урынлы ачуланалар, алар, чүп үләннәре күп булганлыктан үзләренең комбайннарын тиешенчә йөртә алмыйлар.

Сез уйлап кына карагыз, Себердә басулар чүпле булганда да колхозлар гектарыннан 12—13 центнер ашлык җыеп алалар. Әгәр чүп үләннәрен бетерсәң күпме ашлык җыеп алырга мөмкинлекне күз алдына китереп була.

Басуларның чүпләнүенә колхозларның һәм совхозларның мондый игтибарсыз карауларын нәрсә белән аңлатырга? Җир күплек белән: „Гектарлар саны белән алдырырбыз, икмәк барыбер җитәчәк"—кайбер колхоз председательләре һәм совхоз директорлары гына түгел, бәлки кайбер агрономнар да әле хәзергә кадәр әнә шулай фикер йөртәләр.

Сезнең Новосибирск өлкәсендә шулай ук күрше крайларда һәм өлкәләрдә дә әле һаман да пар җирләрен сөрүдә 20—22 сантиметр урнына 13—14 сантиметрга гына сөрү кулланыла икән. Күп кенә колхозлар һәм совхозлар культураларны һич тә чиратлаштырмыйча һәм җирне ял иттермичә, ел саен бодай артыннан бодай чәчеп киләләр. Менә шушы хәл басуларның чүпләнүенә сәбәп була да.

Көнчыгыш өлкәләрдә, шул исәптән сезнең Новосибирск өлкәсендә дә чәчү әйләнешләренә күчә башларга вакыт. Җир күп булган шартларда чәчү әйләнешләрен бөртекле культуралар мәйданын киметмичә башка өлкәләрдә булганга караганда шактый җиңелрәк кертергә мөмкин.

Шулай ук туңга сөрү планнарының да елдан-ел үтәлми килүен бетерергә кирәк. 1939 нчы елны Новосибирск өлкәсе туңга сөрү планын бары 34 процентка гына, Омск өлкәсе 36 процентка, Алтай крае 33 процентка, Красноярск крае 26 процентка гына үтәгән. Болай эшләү дөрес түгел. Гомумән, бездә кайбер урыннарда көзге эшләргә, ягни уҗым чәчүне һәм туңга сөрүне вактында үткәрүгә бәя биреп җиткермиләр, киләсе елның уңышы һәм язгы чәчүнең кыска сроклары нак менә көзге эшләргә бәйләнгәнлекне онталар.

Игеннәрне урып-җыйганда ашлыкның бик күп югалуын да бетерергә кирәк. Бу югалтулар комбайннарның канәгатләнерлек эшләмәүләреннән, урып-җыюны соңга калдырудан, сугуда артта калудан, ындыр табакларында ашлыкның бозылуыннан килеп чыгалар. Урып-җыйганда гектарыннан 2 һәм хәтта 3 центнер ашлыкны югалту кайбер колхозлар һәм совхозлар өчен гади күренеш.

Игенчелекне һәм иген уңышын тагын да күтәрү белән бер үк вакытта колхозларда һәм совхозларда терлекләр санын һәм терлекләрнең продукт бирүен арттыру буенча да көчле эш барырга тиеш. Моның өчен сезнең Новосибирск өлкәсендә, шулай ук сезнең белән күрше булган өлкәләрдә һәм крайларда да мөмкинлекләр бик зур.

Ләкин көнчыгыш районнарны бөртекле ашлык җитештерү буенча СССР ның төп базаларыннан берсенә әйләндерү өчен югарыда саналган чаралар гына җитми күрәсең. Әлегә кадәр эшләнми яткан 6—8 миллион гектар җирне эшләргә кирәк, колхозлардагы һәм совхозлардагы җир запасларына караганда бу бик мөмкин.

Тик бер генә кыенлык бар. Көнчыгыш районнарда игенчелекнең механикалашуы югары дәрәҗәдә булуга да карамастан, мондый зур җир мәйданнарына һаман да колхозлардагы кешеләр җитмәячәк. Ләкин әгәр дә безнең көнчыгыш өлкәләрдәге һәм крайлардагы партия, совет оешмалары һәм колхозлар СССР ның аз җирле башка районнарыннан күчеп килүче колхозчыларны кабул итү һәм урнаштыру эшен оештырсалар бу кыенлыкны бетерү җиңел. Бу яктан караганда Новосибирск өлкәсендәге кайбер колхозларда, мәсәлән, Кемерово районындагы „Путь к социализму" колхозының үзләренә күчеп килүче колхозчылар өчен һәрбер колхозда 2—3—4 йорт салып, яракландырып инициатива күрсәтүләренең гаять зур әһәмияте бар.

Бу яхшы хәрәкәткә төрлечә булышлык итәргә кирәк. Бу хәрәкәт безгә бөтен күченү эшен яңа нигезгә корырга ярдәм итәр. ВКП(б) ның Новосибирск Өлкә Комитеты һәм Өлкә Башкарма Комитеты 1940 нчы елны Новосибирск колхозларына яңа күчеп килүче 20 мең колхозчы семьясен кабул итү өчен хәзерләнергә карар биреп бик дөрес эшләгәннәр. Мондый хәлдә бик күп колхозчыларның яңа шартларда яшәү һәм эшләү өчен көнчыгыш районнардагы колхозларга бик теләп барачакларына шик булырга мөмкин түгел.

Менә, иптәшләр, безнең гаять бай көнчыгыш өлкәләребездә һәм крайларыбызда социалистик игенчелекне тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрү өчен һәм шулай итеп якындагы 2—3 ел эчендә ел саен 2—2,5 миллиард пот ашлык җитештерү өчен шуларны эшләргә кирәк. Күрәсез, монда мөмкин булмаган бер нәрсә дә юк. Сез, шушы киңәшмәдә 1940 нчы елны гектарыннан йөз пот иген уңышы алу йөкләмәсе алып мөраҗәгат кабул итеп бу йөкләмәне намус белән үтәрсез дип ышаныч белдерергә рөхсәт итегез (көчле кул чабулар).

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

ОРЛЫК БЕЛӘН ҮЗАРА ЯРДӘМЛӘШҮ

Шөгер районында колхозларның бер-берсенә орлык белән булышлык күрсәтүләре көннән-көн җәелә. Шул эшне оештыру нәтиҗәсендә хәзерге көндә райондагы 49 колхозның 35 е чәчү орлыклары белән тулысынча тәэмин ителделәр инде. Орлык белән ярдәмләшү дәвам итә. „Урта Чишмә" колхозы „Кызыл Орден" колхозына 60 центнер солы, „Индустрия"- колхозына 10 центнер бодай, „Яш көч" колхозы „Кызыл Октябрь" колхозына 25 центнер бодай һәм 51 центнер солы бирделәр.

***

Урдалы авыл советына караган „Урта Чишмә" колхозында язгы кыр эшләренә атларны хәзерләүгә җидди игтибар бирелә. Бу эштә стахановчылардан Шәрипов һәм Низамов иптәшләр башкаларга үрнәк күрсәтәләр. Алар карый торган атларның хәле бик яхшы. Ат караучылар үзара ярышып эшлиләр. Алар атларга азыкны эшкәртеп ашаталар. Азыкка экономия ясыйлар. Бу колхозда хәзерге көндә түбән көрлектә бер генә ат та юк.

В. Хәлимев.

ОТЛИЧНО һӘМ ЯХШЫ БИЛГЕЛӘРЕНӘ

Буденный районының Әлши һәм Буденный МТС лары үткән елны производстводан аермыйча хатын-кызлардан 23 тракторчы хәзерләгәннәр иде. Үткән елның ноябрендә һәр ике МТС янында тракторчылар хәзерләү буенча оештырылган бишәр айлык курслар үзләренең эшләрен уңышлы итеп тәгәлләделәр. Бу курсларда укучыларга шушы көннәрдә чыгарыш булды. Буденный МТС ы янындагы курсны 36 кеше тәмам итте. Шуларның 17 се сынауларны отлично һәм яхшы билгеләренә тапшырдылар. Курсны бетергән кешеләрнең 11 е хатын-кызлар.

Әлши һәм Буденный МТС лары икесе дә тракторчылар белән тулысынча тәэмин ителделәр.

А. Яфизов.

Агротехниканы өйрәнүгә әһәмият бирелми

Кукмара районының „Кустарь" колхозында (Тәмәй авылы) язгы чәчүгә хәзерлек яхшы гына бара. Орлык җитәрлек. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт тәгәлләнгән. Кар тоту планы үтәлгән. Җирле ашламалар хәзерләү эше дә быел канәгатләнерлек бара. Компост ашлама хәзерләүгә аерура әһәмият бирелә.

Язгы чәчүне бу колхозның материаль яктан яхшы хәзерлек белән каршы алуына ышаныч зур. Ләкин колхоз җитәкчеләре язгы чәчүгә хәзерлекнең бик әһәмиятле бер тармагын онталар. Колхозда агротехниканы өйрәнүгә бөтенләй әһәмият бирелми. Хәзергә кадәр хәтта түгәрәкләр дә оештырылганы юк.

Г. Сибгатуллин.

Яш агрономнар эше турында кайгыртмыйлар

(АГРОНОМ ХАТЫ)

Совхозларда һәм колхозларда югары иген уңышы өчен көрәшне оештыруда агрономнар өстенә гаять җаваплы бурыч йөкләнгән. Шуның өчен дә агроном үзенең эшен бик яхшы белергә, квалификациясен һәр вакыт күтәрергә һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендәге барлык яңалыклар белән вакытында таныша барырга тиеш.

Яңа гына эшкә башлаган яш агрономнарга һәм соңгы вакытларда агротехникумны [illegible] карата бу бурыч [illegible]. Ә моның өчен агрономнарга, билгеле, кирәкле әдәбият белән тәэмин итү һәм барлык шартлар булдырылырга тиеш. Ләкин эш шартлары тудыруга кайбер район җир бүлекләрендә һәм МТС ларда җитәрлек әһәмият бирелми.

Мисаль өчен мин Кукмара районын алам. 1939 нчы елда район җир бүлеге агрономнарның бер җыелышын үткәрү белән чикләнде. Колхозларда агрономия укуларын үткәрү өчен Татнаркомзем да программа җибәрү белән тынычлап калды, түгәрәкләрне оештырганда һәм бигрәк тә анда укытканда кулланма булырлык бер нинди әдәбият җибәрмәде.

Үткән елны район агрокалендаре [illegible] шул елгы барлык эшләр тәгәлләнү алдыннан гына (сентябрьдә генә) бастырып таратылды. Быелгы агрокалендарь төзү турында Кукмара район җир бүлегендә дә һәм шулай ук районның МТС ларында да уйлаган кеше юк. [illegible]

Районның Яңиль МТС ында агрономнар турында [illegible]. Хәтта безгә агрономнарга, „һәр вакыт дип әйтерлек кирәк була торган „Советская агрономия", „Селекция и семеноводство" һәм башка шулар кебек журналлар да яздырылмады.

Кирәкле әдәбият булмау, район җир бүлегеннән дә һәм шулай ук МТС тарафыннан да тиешенчә практик булышлык күрсәтелмәү нәтиҗәсендә безгә, яш агрономнарга күп кенә мәсьәләләрдә уңайсыз хәлдә калырга туры килә. Татнаркомзем яш агрономнар эше турында кайчан кайгырта башлар икән.

МТС агрономы.

МТС һәм МТМ алдынгыларының

РЕСПУБЛИКА ПОЧЕТ ТАКТАСЫ

Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда яхшы күрсәткечләр бирүче алдынгылар һәм стахановчылар ВКП(б) райкомнарының һәм хезмәт ияләре депутатларының район советлары башкарма комитетларының күрсәтүләре буенча республика Почет тактасына кертеләләр:

44. Тархан МТС ы трактор бригадасы бригадирлары А. В. Каргин һәм К. Боршков иптәшләр. Аларның бригадалары үзләренә беркетелгән тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1940 нчы елның 10 нчы январена тәгәлләделәр.

45. Апас районының Дәүләки МТС ы трактор бригадасы бригадирлары Г. Гыйбадуллин, З. Гайфуллин, Г. Хәерев иптәшләр. Алар җитәкчелек итә торган бригадаларда тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау 1940 нчы елның 15 нче январена тәгәлләнде.

ЯРЫШ ИНИЦИАТОРЫ БУЛГАН РАЙОНДА

(Махсус хәбәрчебездән)

ПУЧЫ. (Телефон буенча). Язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнү өчен ике район арасында төзелгән социалистик ярыш договорының үтәлешен тикшерү буенча Актаныш районы делегациясе Калинин районында булды.

Калинин районы быел һәр гектардан 100 пот иген уңышы алу өчен көрәшкә чакыруның инициаторы. Йөзпотчылар хәрәкәтен башлап җибәрүче район чәчүгә хәзерлектә күп кенә уңышларга ирешкән. Язгы чәчү өчен кирәкле орлыкның 90 проценты хәзерләнгән һәм 80 проценты чәчүгә яраклы кондициягә җиткерелгән. Җитешмәгән чәчү орлыгын урында табу чаралары күрелә. Наркомзем планы буенча быел колхоз басуларына өч йөз мең йөк тирес чыгарылырга тиеш. Район бу планны 500 мең йөккә үтәү өчен йөкләмә алган иде. Колхоз басуларына 300 мең йөк чамасы тирес чыгарылган инде. Ә үткән ел бу вакытта басуга тирес чыгару планы бары 31,7 процентка гына үтәлгән булган. Басуда кар тоту планы үткән ел 26 процентка үтәлгән булса, быел 97,3 процентка үтәлгән. Язгы чәчүгә кирәкле авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау эшләре тәгәлләнү алдында тора. Агротехниканы өйрәнү буенча 294 түгәрәк һәм 8 урында стахановчы мәктәпләр эшли. Түгәрәкләрдә 4.851 кеше, стахановчы мәктәпләрдә 297 кеше укый. 5—6 көнлек курслар аша 220 яровизатор, 10 көнлек курста 47 агротехник хәзерләнгән.

Районның аерым колхозларында язгы чәчүгә хәзерлек буенча үрнәк булырлык тәҗрибәләр бар. Актаныш район делегациясе бу колхозларның тәҗрибәләре белән нык кызыксынды. Үрәзмәт авылы Ленин исемендәге колхозда барлык орлыклар хәзерләнеп, чәчүгә яраклы кондициягә китерелеп куелган. Аларның сакланышы яхшы. Колхоз чәчү орлыклары җитмәгән башка колхозларга, яңа уңыштан түләү шарты белән, 794 центнер чәчү орлыгы биргән. Агротехника чараларын үткәрү планы тулысынча үтәлгән. Барлык машиналарга һәм инвентарьга яхшы сыйфатлы итеп ремонт ясалган. Колхоз язгы чәчүгә чыгарга хәзер тора.

„Дил", „Кызыл юл № 1" колхозлары да язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнгәннәр. Бу колхозларда культура-масса эшләренә нык әһәмият бирелә. „Дил" колхозында 429 колхозчы агротехника түгәрәкләрендә укый, бригадаларда һәр 10 көн саен стена газеталары чыгарыла. Колхоз һәм бригадалар арасында социалистик ярыш договорлары төзелгән, аларның үтәлеше тикшерелеп барыла. Колхозда хезмәт дисциплинасы яхшы һәм стахановчылар саны көннән-көн үсә.

Билгеле, делегация районның язгы чәчүгә хәзерлек эшләрендә әле җидди кимчелекләр барлыгын да әйтте. МТС та тракторларга ремонтның сыйфаты канәгатләнерлек түгел. Язгы чәчү өчен тагын 20 тонна ягулык, майлау материаллары ташыйсы бар. Производство планнарын төзү бик акрын бара.

Районда 63 колхозның 12 сендә генә производство планнары төзелгән. Даими һәм ефремовчы звенолар оештыру мәсьәләләре буенча район оешмалары һәм колхоз җитәкчеләре җитәрлек шөгылләнмиләр. Бу эшкә конкрет җитәкчелек юк.

Колхозлардагы терлекчелек фермаларына зоотехника һәм ветеринария ярдәме күрсәтү тиешенчә куелмаган. „Ленин бүләге" колхозында атлар аерым караучыларга бирелмәгән. 32—33 баш атка ике караучы бар. Алар атларны көн аралаш чиратлашып карыйлар. Ә хезмәт көне көн саен языла. Вактында карамау, тәрбияләмәү аркасында кайбер атлар ябык. „НОТ" колхозында камыт тигереп, ыңгырчак суктырып байтак атны сафтан чыгарганнар.

Мондый аерым җитешсезлекләр һәрбер колхозга индивидуаль якын килеп җитәкчелек итмәү нәтиҗәсендә килеп чыкканнар.

Делегация күрсәткән бу җитешсезлекләрне Калинин районы, һич шиксез, ашыгычлык белән бетерер.

А. Вәлиев.

Драматургиябез алдындагы бурычлар

Совет драматургиясе соңгы елларда зур уңышларга иреште. Бу уңышларның иң күренеклесе һәм әһәмиятлесе итеп рус драматургиясендә бөек юлбашчыларыбыз Ленин, Сталин образларының чагылуын күрсәтергә кирәк. Драматург Погодинның „Мылтыклы кеше" се, А. Корнейчукның „Чынлык" дигән әсәре һәм, ниһаять, Каплер белән Златорованың „Ленин" е бу җаваплы бурычны чишүдә уңышлы үрнәкләр булып торалар.

Рус совет драматургиясе белән берлектә һәм аның уңышлы үрнәкләре тәҗрибәсендә, СССР дагы башка халыкларның драматургиясе дә көннән-көн үсә бара.

Татар совет драматургиясенең сизелерлек үсеше соңгы елларга туры килә. Бу үсешне без бигрәк тә Татар Дәүләт Академия театрының репертуары яктысында ачык күрәбез. Элек репертуарның иң зур өлеше тәрҗемә әсәрләрдән тора торган бу театрда без оригиналь әсәрләрнең елдан-ел арта баруын күрәбез. Шуның белән бергә, бу әсәрләр художество сыйфатлары, жанр һәм тематика төрлелекләре белән дә туктаусыз күтәрелүгә табан баралар.

Соңгы елгы драматургиябездә тарихи шәхесләрне, тарихи вакыйгаләрне чагылдырган катлаулы темаларга кыюырак тотыну күзгә бәрелә. Без бу елгы сезонда халкыбызның сөекле шагыйре Г. Тукай һәм аның чордашлары Г. Камал, Х. Ямашев, С. Рәмиләрне гәүдәләндергән „Тукай" (Ә. Фәез) әсәрен күрдек. Сатира планында язылган „Булак арты „республикасы" (Н. Исәнбәт) шулай ук катлаулы тарихи теманы специфик формада чишүнең үрнәге. Ниһаять, Р. Ишмурат һәм Х. Фәтхуллин тарафыннан язылган „Ялкынлы яшьлек" пьесасы безнең әдәбиятта бөек юлбашчы Ленин образын тудыруга булган кыю омтылышның беренче үрнәге.

Драматургиядә халык фольклорын файдалану, халык иҗады нигезендә әсәрләр тудыру буенча уңышлы адымнар ясалды. Шундыйлардан орденлы драматург Тажи Гыйззәтнең „Кыю кызлар" ын күрсәтергә кирәк.

Бу фактлар соңгы елларда татар совет драматургиясендә зур гына алга китеш барлыкны күрсәтәләр. Ләкин бу яш драматургия алдында торган гаять зур бурычларны тулысынча тормышка ашырудан ерак тора әле. Югарыда саналган уңышлы яклар—алар башлангыч омтылышлар булып кына торалар. Шул омтылышларны киң җәелдерү нигезендә, татар совет драматургиясен яңа югарылыкка күтәрергә, массаны тәрбияләүнең тагын да көчле коралына әйләндерергә кирәк.

Татар драматургиясенең иң зур җитешсезлеге—бүгенге тематикадан, бүгенге политик актуаль проблемалардан артта калуында. Илебездә социализм төзелеше яңадан-яңа җиңүләргә ирешә. Һәрбер җиңү җәмгыятебезнең коммунизмга күчә баруын билгели һәм коммунизмга хас булган яңа сыйфат арттыра. Стахановчылык хәрәкәтенең яңа казанышлары, күп станокчылар, катлаулы техниканы үзләштерү, фән хезмәте белән акыл хезмәтенең аермасы бетүгә таба булган юнәлеш, төзелештә хатын-кызның роле үсү, авыл хуҗалыгында яңа үсеш һ. б. гаять зур әһәмияткә ия булган тарихи факторлар. Ләкин безнең әдәбият боларны бик йомшак чагылдыра әле. Безнең әдәбиятта оборона темасының артта калуы аеруча нык күзгә бәрелә. Хәзерге шартларда илнең оборона көчен ныгытуның политик әһәмиятен сөйләп торасы да юк. Әдәбиятның бу мөһим политик мәсьәләдән артта калуы аның сугышчан корал булу көчен йомшарта.

Әгәр Татар Академия театрының бу елгы сезонына күз салсак, бүгенге көнне чагылдырган әсәрне бөтенләй диярлек тапмыйбыз.

Драматургиябездә һәм театрыбызда бүгенге көннең яңа кешесе образын, җитәкче большевик типын тудыруның йомшак торуын әйтми калып булмый. Драматургия һәм театр (режиссура) сокланырлык эшләнгән, тулы канлы уңай образ тудыра алганнары юк әле. Хәзерге сәхнәдә барган әсәрләр мулла, хаҗи, абстай, сәүдәгәр, приказчик типларын гына җанлы эшләп бирә алдылар.

Драматургиябездә иң артта калган бер тармак—масса сәхнәләре, колхоз-совхоз, эшче театрлары өчен әсәрләр тудырылмаудан яки начар сыйфатлы әсәр бирүдән гыйбарәт. Массовый сәхнә әсәрләренә драматурглар игтибарсыз, кечрәйтеп карыйлар. Бу караш тамыры белән ялгыш һәм зарарлы караш. Район, колхоз-совхоз театрлары, үзешчәнлек сәнгате хәзерге көндә чиксез зур роль уйный. Аларны югары сыйфатлы репертуар белән тәэмин итү драматургларның намус эшләре булып тора.

Комедия жанры өстендә эшләүнең җидди бурыч булуын әйтеп үтәргә кирәк. Кешеләрнең аңын яңача тәрбияләүдә комедиянең роле зур. Бездә комедиягә борылыш нык кына сизелә. Ләкин әле совет комедиясенең чын стиле табылды дип әйтеп булмый. Күбесенчә бездә комедияне җиңел, арзанлы шарж, кәмитчелек белән алыштыралар. Очраклы положениегә корылмаган, ә чын, реаль типлар тудырган, тирән эчтәлекле совет комедияләре тудырырга кирәк.

Драматургиядә югары художество сыйфаты өчен көрәш төп бурычлардан булырга тиеш. Психологик тулы эшләнгән образлар, тирән эчтәлекле, ышандырырлык вакыйгаләр, җанлы әдәби тел—драматургның төп максаты булсын. Бездә тышкы күренешләр, тышкы эффект белән мавыгу көчле. Күбесенчә безнең театр эшчеләребез язучыны шул юлга этәрәләр. Алар тирән эчтәлекле спектакль эшләү урнына тышкы эффект артыннан куалар. Бу, дөрес түгел.

Драматургиянең үсешен тәэмин итү өчен, бу бурычлар тирәсендә ныклы оештыру эшләре алып барырга кирәк. Бу бурыч, барыннан да элек, язучылар союзы өстенә төшә. Татарстан Язучылар союзы драматургиягә аерым зур әһәмият биреп, правление каршында драматургия эшләре буенча даими комиссия төзеде. Бу комиссия актуаль темаларга әсәрләр тудыру, массовый пьесалар бастырып тарату, театр тәнкыйтен күтәрү, совет эстрадасын баету буенча планлы эш алып бара. Бу эшләр буенча конкрет чаралар үткәреләләр.

Драматургиянең үсешендә театрларның роле бик зур. Ләкин театрлар язучылар белән начар эшлиләр. Татар Академия театры работникларының кайберләре язучыларга: „икмәк корсак артыннан йөрми" формуласы аша гына карыйлар. Дәүләт филармониясе, Халык Иҗады Йорты үз репертуарлары өстендә эшләү турында аз гына да кайгыртмыйлар.

Киләчәктә бу оешмаларда репертуар мәсьәләләре белән кызыксынуны арттырырга, театрлар белән язучылар союзының бәйләнешен көчәйтергә кирәк. Бөек чорыбызга җавап биргән югары сыйфатлы драма әсәрләре тудыру—язучыларның намус эшләре булып тора.

М. Җәлил.

Чит илләрдә

ШВЕЦИЯ РЕАКЦИЯСЕ ТЫНЫЧЛАНМЫЙ

СТОКГОЛЬМ, 21 март. (ТАСС). Совет—Финляндия солых договоры Европаның төньягында сугыш уты кабызучыларның планнарын җимерде. Үз хужаларының теләген үтәп, Швеция реакциясе Совет—Финляндия солых договоры төзелгәч ук, Скандинавиянең нейтралитетен өзүгә юнәлдерелгән котыруларын яңа кампания белән җәелдерде. Бу юлы Скандинавия реакциясенең барлык көчләре Швециянең, Норвегиянең һәм Финляндиянең „оборона союзы" дип аталган нәрсә тирәсенә берләштерелгән. Швеция реакционерлары үзләренең кампанияләрен „бөтен Швеция һәм Норвегия политикасының нигезләрен яңадан карау", ягъни нейтралитет политикасыннан баш тарту лозунгысы астында алып баралар.

Бу „идея" дә бер нинди дә яңа нәрсә юклыкка ышану өчен бу „оборона союзы"ның тәүге планының „чыганаклары"на күз салу гына да җитә. Скандинавия илләрен сугышка тартырга маташкан көчләр „оборона союзы" дигән нәрсәгә өндәп, шул ук юнәлештә хәрәкәт итүләрен дәвам итәләр. Норвегиядә чыга торган „Арбейдерен" газетасы болай дип яза: „Сугышчан кинәйтергә тырышучы кеше хәзер оборона союзы төзүне веруча агрессив тестә якладылар. Алар бу союзның СССР га каршы юнәлдерелгәнлеген яшермиләр".

Шушы көннәрдә генә Стокгольмдә иң зур зал булган „Аудиториум" да митинг булды. Бу митингда Швециядәге „активистлар" хәрәкәтенең лидерлары—майор Хеглунд, генерал Окерман һәм башкалар сөйләделәр. Хеглунд „оборона союзы" төзү кирәклеге политик яктан „нигезләнгән" чыгыш ясады. Ул, Швеция сугыш чукмарларының реакцион өлеше вәкилләре мәсьәләнең хәрби ягына тукталдылар.

Үзенең кабәхәт һәм Советка каршы һөҗүм белән тулы булган речендә Хеглунд Швециянең нейтралитетен бетерергә кирәклеге турында тырышып исбат итәргә маташты.

Бу митингта сугыш чукмарларының реакцион өлеше белән Хеглунд группасы арасында үзенә бер төрле туганлашу булды. Гайрәтле генерал Окерман провокатор Хеглундка күтәренке рух белән [illegible] һәм үзенең иске дошманының аның белән бер трибунада торып [illegible] идеясен гәүдәләндерүен әйтте. Генерал революцион эшчеләргә каршы террорны көчәйтүне, сугыш чукмарларына ошамый торган политик дошманнардан үч алуны, Швеция армиясенә аяк [illegible] артыруны турыдан-туры таләп итте.

Швеция армиясе генеральный штабының хәзерге начальнигы генерал-майор Юнгнин 1930 нчы елны чыгарылган китабының бу союзның „кирәклеген" нигезли торган „программ" документларының берсе булуы „оборона союзы" тирәсендә күтәрелгән бөтен шау-шуны ачыкландыра. Бу китабында Юнг 1930 нчы елны ук инде Советлар Союзына каршы көрәшү теләге белән төньяк илләрен берләштерү „программасын" язган иде.

Ләкин „активистлар" ның бу шау-шулары барсы да массаның протестына һәм Швециянең тынычлыгын һәм нейтралитетын саклау турында кайгыртучы кешеләрнең җитди каршылыкларына китерәләр. Шушы көннәрдә генә Швециянең юл эшләре министры либерал Андерсон [illegible] шәһәрендә сөйләгән речендә активистлар матбугаты Швеция җәмгыятьчелегенең тыныч настроениесен чагылдырмый дип белдерде. Ул болай диде: „Соңгы көннәрдә матбугатта язылган нәрсәләр характерлы түгел. Газеталар җәмгыятьчелек фикеренә йогынты ясарга тырышкан хәлдә дә алар җәмгыятьчелек фикерен чагылдыралар дип әйтеп булмый".

Сугыш уты кабызучыларның провокацион юлларына каршы протестлар көн саен газеталарда да чагыла. Либераль „Дагбладет" газетасы болай дип яза: „Соңгы елларда Скандинавия илләренең берләшеп эш итүләре [illegible]. Скандинавия илләре белән Скандинавиядәге башка илләр арасында бер нинди хәрби союз юк иде. Ул безгә кирәк түгел". „Оборона союзы" турында сүз [illegible] мондый союзны „ут белән шаяру" дип атыйлар. Газета болай дип яза: „[illegible]".

„Арбейдерен" газетасы болай дип яза: „Мондый союз [illegible]". „Әгәр Норвегия хөкүмәте һәм парламент Швеция һәм Финляндия белән оборона союзы төзергә [illegible]".

„Ню даг" газетасының фикеренчә, „активистлар" СССР га каршы „оборона союзы" формасында реванш идеясен җәелдерергә тырышалар. Газета болай дип яза: „Ләкин фин халкы бу карашка [illegible]. Үзенең тынычлыгын тәэмин итү өчен Швеция кебек ук Финляндия дә Советлар Союзы белән [illegible] кызыксына. Сугыш уты кабызучылар агентурасы [illegible]. Тыныч политика юлы [illegible] бәйсезлек һәм Швеция халкының яхшы тормышы юлы булырга тиеш".

ӘФГАНСТАН ГАЗЕТАСЫНЫҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

КАБУЛ, 21 март. (ТАСС). СССР ягыннан Әфганстанга каршы һөҗүм булуы белән „Ислах" газетасында түбәндәге хәбәр басылган: „Соңгы вакытта кайбер чит ил газеталары гуя СССР дан Әфганстанга һөҗүм куркынычы булу турында һәм Әфганстанның сугышка хәзерләнүе турында хәбәрләр таратып маташалар. Аерым алганда мондый хәбәрләрне Мисыр газеталары [illegible]. Мәсәлән, Мисырда чыга торган [illegible] журналы 26 нчы февраль номерында [illegible]. Элеккеге кебек ук без бу хәбәрләрне юкка чыгарабыз [illegible]".

[illegible]

Аннары „Ислах" газетасы болай дип яза: [illegible].

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. 6 көн буена сузылган каты сугышлардан соң кытай гаскәрләре Наньчиннан төньяк-көнчыгыштарак Линшанга [illegible].

[illegible]

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. [illegible]

ВАН ЦЗИН-ВЕЙ „ХӨКҮМӘТЕ"Н ТӨЗҮ

ШАНХАЙ, 21 март. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Нанкин конференциясе „Кытайда яңа хөкүмәт" төзү турында 20 нче мартта карар кабул иткән.

ЧЕМБЕРЛЕН РЕЧЕ

ЛОНДОН, 21 март. (ТАСС). Рейтерның хәбәр итүенә караганда, түбәнге палатада баш министр Чемберлен, башлыча Совет—Финляндия арасында төзелгән солых договорына багышлап речь сөйләгән. Речьнең эчтәлегеннән күренгәнчә, ул, Англия һәм Франция тарафыннан Финляндиягә ярдәм күрсәтү эшендә гаять зур тырышлык куелганлыкны һәм бу тырышлык алар көткән нәтиҗәләрне бирмәгән икән, монда башлыча Англия—Франция гаскәрләрен үз территорияләре аркылы үткәрүдән баш тарткан Швециянең һәм Норвегиянең гаепле икәнлекләрен күрсәтергә маташкан. Чемберлен Англиядән Финляндиягә җибәрелгән сугыш материалларын санап чыккан. Ул Германиягә ташланган, имештер, Германия гаскәрләр үткәрү турындагы мәсьәлә буенча Швециягә һәм Норвегиягә басым ясаган булган.

Шул ук вакытта Чемберленнең речь Швециягә һәм Норвегиягә карата үпкә белән тулы. Аерым алганда Чемберлен „нейтралитет доктринасы"н тәнкыйть иткән. Имештер, „нейтралитет доктринасы" Норвегия һәм Швеция хәрәкәтләрен өзгән һәм ул „кечкенә нейтраль ил өчен барсын да сынап карау яхшырак, ләкин Германия белән союзниклар арасындагы сугышка тартылмаска кирәк дигән фикергә нигезләнгән булган". Чемберлен Швеция белән Норвегиягә „нейтралитет доктринасы" белән элемтәне өзүне һәм „үзләренә ярдәм итәргә хәзер торучы" „башка илләргә кушылуны" тәкъдим иткән (сүз Англия белән Франция турында бара).

Уэллесның сәяхәтенә һәм Бреннерда Гитлер белән Муссолининың очрашуына кагылып, Чемберлен болай дигән: „бу очрашуның нәтиҗәсе нинди генә булса да без аңа хәзер торабыз һәм бу сугышка кергәндә алдыбызга куйган теләкләребездән баш тартмабыз".

Аннары Чемберлен Германия авиациясенең Скапа Флоуга булган соңгы һөҗүме вакытында 20 ләп бомба ташлаганлыкны белдергән. Бер караб зарарланган. Германия самолетлары Скапа Флоу районында коры җиргә җимерү көче гаять зур булган 121 бомба һәм 500 ләп яндыра торган бомба ташлаганнар.

Сугыш перспективаларына кагылып Чемберлен реченең ахрында болай дигән: „Кайбер кешеләр аеруча кискен политиканы таләп итәрләр. Без хөкүмәт өстенә төшкән барлык җаваплылыкны аңлыйбыз һәм безне авантюрага этәрә алмаслар, авантюра, безнең фикеребезчә, аның уңышлы чыгуы икеле һәм аның куркыныч тудыруы, хәтта һәлакәткә китерүе мөмкин. Без удар ясарга тиеш булган вакыт һәм урын турындагы мәсьәлә иң нык уйланылган карарлар нигезендә хәл ителергә тиеш".

Англия матбугаты хәрби кабинетны үзгәртеп оештыруны таләп итә

ЛОНДОН, 21 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының радио буенча хәбәр итүенә караганда, күп кенә газеталар хәрби кабинетны үзгәртеп оештыруны һәм үзенең составы ягыннан „сугышны аеруча энергияле рәвештә җәелдерергә" булышлык итәрлек кечерәк хәрби кабинет төзүне яңадан таләп итәләр. „Дейли мейл" газетасының политик күзәтчесе, пасха каникулы вактында Чемберлен шушы мәсьәләне карау эше белән шөгылләнәчәк, дип яза. Политик даирәләр, Чемберлен хәрби кабинет министрләрен департамент эшләреннән азат итәр, дип уйлыйлар.

ФРАНЦИЯ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ЯҢА СОСТАВЫ

ПАРИЖ, 21 март. (ТАСС). Поль Рейно түбәндәге составта яңа кабинет төзеде: министрләр советы председателе һәм чит ил эшләре министры Рейно („Альянс демократик" вәкиле), министрләр советы председателе урынбасары Шотан (радикал-социалист), хәрби министр Даладье (радикал-социалист), юстиция министры Сероль (социалист), эчке эшләр министры Руа (радикал-социалист), финанс министры Ламуре (радикал - социалист), информация министры Фроссар („социалистик һәм республика союзы" вәкиле), диңгез министры Кампинки (радикал-социалист), авиация министры Лоран-Эйнак („сул радикал"), мәгариф министры Сарро (радикал-социалист), колонияләр министры Мандель (бәйсез республикачы), сәүдә һәм промышленность министры Роллэн („Альянс демократик" вәкиле), җәмәгать эшләре һәм транспорт министры Де Монзи („социалистик һәм республика союзы" вәкиле), хезмәт министры Помарэ („социалистик һәм республика союзы" вәкиле), элемтә министры Жюльен (радикал-социалист), сәүдә флоты министры Рио (сул демократ), тәэминат министры Кэй (радикал-социалист), җир эшләре министры Теллье („Альянс демократик" вәкиле), кораллар министры Дотри (группировкалардан тыш), сәламәтлек саклау министры Эро („Альянс демократик" вәкиле), пенсияләр министры Ривьер (социалист), блокада министры Моннэ (социалист).

Шулай итеп хөкүмәт составында 8 радикал-социалист, 3 социалист, 4 „Альянс демократик" вәкиле, 3 „социалист һәм республика союзы" вәкиле, 1 „сул радикал" партия вәкиле, 1 бәйсез республикачы, 1 сул демократ һәм 1 партиясез бар.

Хөкүмәтнең яңа составына элекке кабинеттан түбәндәгеләр кермәделәр: элекке блокада министры Перно, элекке юстиция министры Боннэ, элекке мәгариф министры Дельбос, элекке пенсияләр министры Бесс, элекке сәүдә министры Жантэн, элекке сәламәтлек саклау министры Рюкар, элекке авиация министры Гила Шамбр.

Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендәге шәһәрләрдә. РӘСЕМДӘ: Эшче-крестьян милициясенең милиционеры Белосток шәһәренең Советская урамында хәрәкәтне тәртипкә сала. Д. Чернов фотосы (ТАСС фотохроникасы).

ФӘН-ТЕХНИКА ЯҢАЛЫКЛАРЫ

АКАДЕМИК Т. Д. ЛЫСЕНКОНЫҢ ЯҢА ЭШЕ

Чәчү әйләнешләренә күп еллык үләннәр кертү — колхозларның һәм совхозларның иң әһәмиятле бурычларыннан берсе. Күп еллык үлән чәчүлекләре, терлекчелек өчен азык базасы булдыру белән бергә, туфракның уңдырышын күтәрәләр, бөртекле һәм техник культуралар уңышын бик нык арттыралар. Ләкин күп еллык үләннәрнең, бигрәк тә люцерна кебек кыйммәтле культураларның уңышы канәгатьләнерлек түгел.

Академик Т. Д. Лысенко, Бөтенсоюз селекция-генетика институты (Одесса) сотрудниклары группасы белән Украина көньягының корылыклы даласында люцерна уңышын күтәрү мөмкинлеген өйрәнеп, аны үстерүнең яңа юлын тәкъдим итте.

Гадәттә бу культураның орлыклары яз көне, иртә чәчелә торган бөртекле культуралардан соң чәчеләләр. Чүп үләннәре һәм корылык шартларында чәчүлекләр көчсез булып үсәләр, кышны начар үткәрәләр һәм югары уңыш бирмиләр.

Академик Лысенконың тәкъдиме буенча люцерна орлыклары лущить ителгән һәм яхшы сөрелгән җиргә августта чәчелделәр. Көз көне тишелеп чыккан люцерна кышка кадәр бик яхшы үсте һәм икенче елны югары уңыш бирде. Һәр гектардан 3 центнер уңыш алыйды. Әгәр дә чәчүлек печән өчен чабып алынган булса иде, аның уңышы гектардан 40—50 центнерга җиткән булыр иде.

Быел Украинаның көньяк колхозларында люцернаны көздән чәчү киң кулланылачак. Көз көне Кырымда һәм Төньяк Кавказда урып-җыеп алынган иген җирләренә люцерна чәчү тәҗрибәсе үткәрергә уйланыла.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҮСЕМЛЕКЛӘРЕН ЯСАЛМА СЕРКӘЛӘНДЕРҮ

Агроном А. С. Мусийко тәкъдиме буенча, Украина, Краснодар крае, Воронеж һәм башка өлкәләрнең колхозлары кукурузны һәм көнбагышны ясалма серкәләндерү буенча киң күләмдә тәҗрибәләр үткәрделәр. Йөз мең гектардан артык мәйданда үткәрелгән бу тәҗрибәләр яңа агротехника алымының бик файдалы икәнлеген күрсәттеләр. Кукуруз чәчүлекләре бик яхшы нәтиҗәләр бирде. Николаев өлкәсе, Калининдорф районы, „Путь к социализму" колхозында кукурузны ясалма серкәләндерү 40 гектар мәйданда үткәрелде. Ул кукуруз уңышын гектарына 6 центнерга арттырды. Одесса өлкәсе, Фрунзе районы, Молотов исемендәге колхозда ясалма серкәләндерелгән чәчүлекләрдә кукуруз уңышы һәр гектарга уртача 13,7 центнерга артты.

Иптәш Мусийко методы белән алынган орлыклар күп югары уңыш бирәләр. Одесса өлкәсе, Фрунзе районы, „Перекоп" колхозында 56 гектар мәйданга ясалма серкәләндерелгән участклардан алынган кукуруз орлыгы чәчелгән иде. Һәр гектардан 30 центнер кукуруз алынды. Гади орлык чәчелгән участкыларда исә уңыш бары 20,3 центнер гына булды.

Көнбагышны ясалма серкәләндерү тәҗрибәләре зур нәтиҗә бирде. Краснодар крае, Славянск районы, Карл Маркс исемендәге колхозда бу тәҗрибәләр 15 гектар мәйданда үткәрелде. Нәтиҗәдә уңыш һәр гектардан 6,8 центнерга артты.

СССР Наркомземы колхозларга көнбагышны һәм кукурузны ясалма серкәләндерүне киң күләмдә үткәрергә тәкъдим итте.

ӨШЕГӘН ОРГАННАРНЫ ФИЗИОТЕРАПИК ДӘВАЛАУ

Күптән түгел, бик суык көнне, укучы Г. дача поездының баскычында ярты сәгать чамасы тоткага ябышып барган. Вокзалдан аны профессор В. В. Гориневскаяның Травматология клиникасына җибәрергә туры килгән, чөнки аның беләгенең яртысына кадәр куллары өшегән булган. Озак һәм бик нык сылауга һәм массаж ясауга да карамастан, аның куллары һаман да хәрәкәтсез калган. Бу хәл аның кулларының үле хәлдә калуына, ә соңыннан ике кулының да эшкә яраксыз хәлгә килүенә китерүе мөмкин иде.

Врачлар увч-терапия дип атала торган методны, ягъни үтә кыска дулкыннар белән дәвалауны кулланырга карар биргәннәр. Сеансны өшегәннән соң 3 сәгать үткәч башлаганнар. Шул ук көнне кичкә таба зарарланган урыннарда өстән һәм тирәнтен кан йөреше башланган. Ике көннән соң авырту беткән, авыру үзен шактый яхшы сизә башлаган, температурасы нормаль хәлгә килгән. Клиникада авыру 16 көн яткан. Үтә кыска дулкыннар белән 10 сеанс дәвалаганнан соң ул клиникадан чыккан һәм хәзер сәламәт.

Профессор В. В. Гориневская клиникасында өшегән кешеләрне күзәтү эше бик күп вакыттан бирле алып барыла. Профессор В. А. Милицын һәм дәүләт физиотерапия институтының башка фәнни сотрудниклары тәкъдиме буенча, өшегән кешеләрне дәвалауда увч-терапияне кулланганнар. Өшүнең дәрәҗәсенә карап, 2 дән 22 гә кадәр сеанс үткәрелә. Гадәттә шешенү 4—5 нче көннәрдә, авырту 5—6 процедурадан соң бетә. 20 авыруның берсендә дә тире асты күзәнәкләренең шешүе һәм өшегәннән соң була торган башка төрле өзлегүләр булмаган.

ТАСС сотруднигы белән беседасында дәүләт физиотерапия институтының яралылар бүлеге мөдире профессор В. А. Милицын болай диде:

— Увч—терапияне тагын да ныграк тикшерәсе бар әле. Ул физиотерапевтларның гына түгел, бәлки хирургларның һәм травматологларның да игътибарын үзенә тартырга тиеш.

(ТАСС).

Онытканнар...

Минзәлә китапханәсенең уку залына, гадәттәгечә йөзләрчә укучылар килә башладылар. Китапханәнең татар бүлеге алдына, кулына берничә китап тоткан, яшь кенә бер егет килеп басты да:

— Абый, Шота Руставелинең „Юлбарыс тиресе ябынган батыр" дигән китабын бирегез әле,—дип ачык тавыш белән үзенең таләбен белдерде.

— Рәхим ит, иптәш, диделәр аңа.

Егетебез өстәл янына килеп китапның битләрен ашыга-ашыга актара башлады.

— Ләкин битлесен бирегез,—дип кинәт әйтеп куйды ул.

— Ничек битлесен? Китаплар битле булалар инде,—дип китапханәче аңа җавап кайтарды. Егет елмайды да:

— Әле шуны да белмисезме? Менә карагыз, дип 74 нче битне тиз генә ачып салды. Чынлап та китапның 74—75 нче битләре коры ак кәгазьдән генә тора иделәр. Егет тагын:

— Юк, юк, сез алгарак барыгыз,—дип куйды.

Яшен тизлеге белән китап битләрен актарабыз... 78, 79, 82, 83, 86, 87 нче битләргә, ичмасам, күңел өчен дә бер хәреф басылмаган. Барыбызның да күзләребез шар булды. Егет тагын елмайды:

— Юк, юк, сез тагын „Гарибальди" дигән китапны алыгыз әле, дип, әре генә итеп, әйтеп куйды ул. Алдык. Ни күзебез белән күрик, ул китапта 24 нче биттән башлап 30 нчы биткә чаклы барлык битләр ике тапкыр басылганнар. Әсәрнең азагы бөтенләй юк. Аның урнына 17 нче битне ябыштырганнар.

Без иркенләп „уф!" дип әйтергә өлгермәдек, егетебез „Эстрада" дигән җыентыкны куеныннан чыгарып салды. Бу китапның да 146, 147, 150, 151, 154, 155, 158, 159 нчы битләре ап-ак иделәр. Аларда бер хәрефнең дә эзе юк. Менә инде „уф" дип торырга урын юк иде. Без, укучылар, Татгосиздат адресына атап менә шуңа ачык сорауны бирергә булдык. Мондый бракларга кайчан чик куелыр икән? *Г. Бикмул.*

Елгаларда

15 нче марттан бирле Волгада һәм Камада су арта башлады. Бер атна эчендә Вязовые янында Волга суы 31 сантиметр, Югары Ослан янында—29 сантиметр, Кама Тамагы янында—31 сантиметр артты. Алабуга һәм Лаеш янында Кама суы тәүлеккә 2—4 сантиметр артып тора.

Иж елгасының суы Әгерҗе янында 61 сантиметр, Казанка суы Арча янында 171 сантиметр арткан иде. Соңгы вакытта һавалар салкынаю сәбәпле Иж һәм Казанка сулары, шулай ук башка вак елгаларның сулары яңадан кими башлады.

КОЛХОЗ ЮРГАЛАРЫ

Татарстан республикасының колхозларында нәселле юргалар саны шактый үсте. Хәзер аларның гомуми саны 7.000 баштан артык.

Республикада 9 урында колхозара тренировка пунктлары эшли. Бу пунктларда колхозларның 165 баш тайлары тренировка үтәләр.

„Восток" (Тельман районы), „Гигант" (Буденный районы) колхозларының һәм башкаларның тренировка пунктлары инде үзләре тәрбияләгән юргаларны Казан ипподромына җибәрәләр.

Казанның республика ипподромы быел колхозларның 215 иң яхшы юргаларын, чабыш атларын сыначак.

„Привет Сталину" колхозының (Алексеевский районы) тренировка пунктында тәрбияләнгән „Астра" исемле ат 6 нчы мартта Мәскәүнең Бөтенсоюз ипподромында чыгыш ясады. 3 яшьлек юргалар өчен булган чабышларда „Астра" 1.600 метр дистанцияне 2 минут 29,1 секунд эчендә үтте. „Астра" 1940 нчы елгы авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә кандидат итеп билгеләнде.

М. Бакаев.

СУД

ТАЛАУЧЫЛАР

Сталин районының 1 нче участкы халык судында Г. Гарипов, Гани Закиров һәм Сибгат Сабиров дигән кешеләрнең эше каралды. Алар узган елның 18 нче декабрендә кич Киров урамының 24 нче йорттагы сыра залында Петрушин дигән кеше белән танышканнар. Петрушин исереп җиткәч, Гарипов аны „Әйдә өенә алып кайтам" дип урамга алып чыккан да, үзенең иптәшләре белән бергә шәһәр белән Кызыл Армия бистәсе арасындагы дамбага алып барган. Алар анда Петрушинның доха толыбын, костюмын һәм 100 сум акчасын талап алганнар.

Халык суды Гариповны 10 елга, Закировны һәм Сабировны 3 әр елга ирекләреннән мәхрүм итүгә хөкем итте.

БЕЛДЕРҮ

24 нче март, көндез 12 сәгатьтә Укытучылар йортында (Островский урамы, 10) ата-аналар университетының чираттагы занятиесе үткәрелә. Тема: „Кечү яшьтәге укучы балаларның психологик характеристикасы". Лектор—профессор Красников.

Мәктәп җитәкчеләре ата-аналар университетының тыңлаучылары булып билгеләнгән барлык ата-аналарның занятиегә килүләрен тәэмин итәргә тиешләр.

Казан Шәһәре Мәгариф бүлеге.

Редактор урынбасары
И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

ТАТНАРКОМПРОС һӘМ УКЫТУЧЫЛАРНЫҢ КВАЛИФИКАЦИЯЛӘРЕН КҮТӘРҮ ИНСТИТУТЫ
ТЕЛ һӘМ ӘДӘБИЯТ УКЫТУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЕНЧА
шушы ел 25 нче марттан 28 енә кадәр, республика күләмендә
ФӘННИ ПЕДАГОГИК КОНФЕРЕНЦИЯ
үткәрүне оештыралар
Конференциягә Казан шәһәре мәктәпләрендә татар, рус һәм Европа телләре укытучылар чакырылалар.
Конференция 25 нче март көндез 10 сәгатьтә Укытучылар йортында (Островский урамы, 10) ачыла.
533—1

КАЗАН ШӘҺӘРЕ СТАЛИН РАЙОНЫ
ПИОНЕРЛАР ЛАГЕРЫ КОМИССИЯСЕ
1940 нчы ел сезонында пионерлар лагерына путевкалар алырга теләгән учреждениеләр һәм оешмалар белән
ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ БАШЛАДЫ
Казан, Киров урамы, 70, бүлмә № 25. Иптәш Вәлиуллинга мөраҗәгать итәргә.
527—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
24 нче мартта көндез
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
кич ИРЕК
25 нче мартта Зур театр бинасында
ФАУСТ
Талоннар белән кертелми.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 23 нче мартта һәм 24 нче мартта кич
МАСКАРАД
24 нче мартта көндез
ЛЕНИН
Талоннар белән кертелми.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
(Һәр көн 3 пар көрәшә)
һәм зур программа буенча
ЦИРК УЕНЫ
24 нче мартта
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Уеннар: көндез 12 дә,
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

Киров районындагы
КУЛЬТУРА САРАЕНДА
Яшь Тамашачылар театры спектакльләре
23 нче мартта
БАЛЬЗАМИНОВНЫҢ ӨЙЛӘНҮЕ
24 нче мартта
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар белән кертелми. Кич 8 дә башлана.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, яңа кино-комедия ТАШЛАНДЫК
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ПРЕМЬЕРА ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	КЕЧКЕНӘ АНА
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9 - 30 да.	ҖИР ПЛЕНДА
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	Гроза
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	ПАТРИОТ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП

КИРӘК:
ТатТАСС редакциясендә эшләү өчен, ТАТАР һәм РУС ТЕЛЛӘРЕН БЕЛҮЧЕ СТЕНОГРАФИСТКА. Бауман урамы, Матбугат йорты, 3 нче кат, 52 нче бүлмә.
446—3—3

Серго Орджоникидзе исемендәге заводка югары КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ОБОЙЧЫЛАР һәм СТЕНОГРАФИСТЛАР. Заводның кадрлар бүлегенә килергә.
459—4—3

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 686 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1120.